# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 8
(I бүлек)
август

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№8*
*(I бүлек)*
*август*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы №2635
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

## Эчтәлек

653. «Татарстан Республикасының Җир кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 4

654. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 4

655. «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 13

656. «Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 15

657. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 44

658. «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 75

659. «Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ......... 90

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 653. Татарстан Республикасының Җир кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

1 статья. Татарстан Республикасының Җир кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, № 8) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 6 статьяга түбәндәге редакциядә 6 пункт өстәргә:

«6) җир өчен түләү алу буенча законнар нигезендә ташламалар билгеләү».

2. 7 статьяга түбәндәге редакциядә 4 пункт өстәргә:

«4) җир өчен түләү алу буенча законнар нигезендә ташламалар билгеләү».

3. 8 статьядагы 9 пунктны төшереп калдырырга, 10 пунктны 9 пункт дип санарга.

4. 9 статьядагы 11 пунктны төшереп калдырырга.

5. 11 статьядагы 5 пунктны 6 пункт дип санарга.

6. 11 статьяга түбәндәге редакциядә 5 пункт өстәргә:

«5) җир өчен түләү алу буенча законнар нигезендә ташламалар билгеләү».

2 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2251

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 654. Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасының суверенлыгын, Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдыручы Татарстан Республикасының дәүләт символлары Татарстан Рес-

публикасының Дәүләт гербыннан, Татарстан Республикасының Дәүләт флагыннан һәм Татарстан Республикасының Дәүләт гимныннан гыйбарәт була.

Әлеге Законда Татарстан Республикасының дәүләт символларын тасвирлау һәм аларны рәсми куллану тәртибе билгеләнә.

## I булек. Татарстан Республикасының Дәүләт гербы

1 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гербы нигезендә «Татарстан» дип язылган татар халык орнаменты белән каймаланган кояш дискы җирлегендә алгы уң аягын бераз күтәргән, янтавында түгәрәк калканы булган канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт, канатлары җиде каурыйдан тора, калкандагы розеткасы сигез таҗдан тора.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының төсле сурәтендә кояш - кызыл (ачык кызыл кадмий), барс, аның канатлары һәм калканындагы розеткасы - ак, кайма - яшел (ачык яшел кобальт), калканы, каймадагы орнамент һәм «Татарстан» дигән язу алтынсу төстә була.

2 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте түбәндәгеләрдә урнаштырыла:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы биналарында һәм ул барлыкка китерүче органнар, билгеләп куючы, сайлаучы урындагы затлар урнашкан биналарда, Татарстан Республикасы Президенты резиденциясендә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, министрлыклары һәм дәүләт комитетлары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына буйсынучы башка органнар биналарында, Татарстан Республикасы судлары биналарында, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле администрацияләр биналарында, Татарстан Республикасының даими вәкиллекләре биналарында;

2) Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы даими вәкилләренең эш кабинетларында;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышлары уздырылучы залларда, халык депутатларының җирле

Советлары, җирле администрацияләр биналарында, Татарстан Республикасы судларының суд утырышлары залларында, шулай ук тууларны һәм никахларны дәүләт теркәвенә алу урыннарында;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның органнары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм дәүләт комитетлары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына буйсынучы башка органнар, Татарстан Республикасы судлары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты аппаратлары, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы даими комиссияләре, Татарстан Республикасы халык депутатларының, җирле Советлары һәм җирле администрацияләр мөһерләрендә һәм документлар бланкларында, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, дәүләт нотариаль конторалары бирә торган документларда;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының рәсми басмаларында.

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәтен рәсми рәвештә күчереп төшерүнең башка очраклары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

3 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт гербының күчереп ясала торган сурәте, зурлыгына карамастан, әлеге Законга кушылып бирелүче (1 нче кушымта) төсле яисә схематик сурәтенә төгәл туры килергә тиеш.

4 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гербын башка дәүләтләрнең дәүләт герблары белән бергә урнаштырганда Татарстан Республикасы Дәүләт гербының зурлыгы башка дәүләтләрнең дәүләт герблары зурлыгына туры килергә тиеш.

5 статья. Дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре Татарстан Республикасының Дәүләт гербын әлеге Закон нигезләмәләренә туры китереп урнаштыру кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

6 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт гербының эталоны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында саклана.

7 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гербы төшерелгән бланкларны әзерләү, куллану, саклау һәм юкка чыгару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## II бүлек. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы

8 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы яшел, ак һәм кызыл төстәге горизонталь буйлардан торган туры почмаклы тукымадан гыйбарәт. Ак буй флаг киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә, ул яшел (ачык яшел кобальт) һәм кызыл (ачык кызыл кадмий) төстәге бертигез киңлектәге буйлар арасында урнаша. Яшел буй өстә була.

Флаг иңенең буена чагыштырмасы - 1:2.

9 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы түбәндәге урыннарда күтәрелә яисә урнаштырыла:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре яисә Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары сессияләре уздырылучы биналарда - барлык сессия чорына;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы биналарында, Татарстан Республикасы Президенты резиденциясендә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле администрацияләр, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасының даими вәкиллекләре биналарында - даими рәвештә;

3) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, башка дәүләт органнары һәм җәмәгать берләшмәләре, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар биналарында, Татарстан Республикасы милкендә булган елга флоты судноларының борын өлешендәге мачтада, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә бәйрәм көннәрендә һәм истәлекле көннәрдә - торак йортларда;

4) Татарстан Республикасы вәкиллекләре биналарында һәм транспорт чараларында - халыкара хокук нормаларына, дипломатик беркетмә кагыйдәләренә һәм вәкиллекләр урнашкан ил традицияләренә туры китереп.

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы дәүләт органнары һәм җәмәгать берләшмәләре, җирле үзидарә органнары, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр уздыра торган церемонияләр һәм башка тантаналы гамәлләр булганда, шулай ук гаиләләрнең тантаналы гамәлләре вакытында күтәрелергә мөмкин.

10 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышлары залларына, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисенең һәм Татарстан Республикасы Прокурорының, Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетларының, җирле администрацияләрнең, Татарстан Республикасы даими вәкиллекләренең җитәкчеләре хезмәт кабинетларына, халык депутатлары җирле Советлары һәм җирле администрацияләр биналарында, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының транспорт чараларында рәсми гамәлләр үткәрү вакытларында урнаштырыла.

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советы сессияләре эшендә катнашуы вакытында урнаштырыла.

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы Татарстан Республикасы Президенты рәсми рәвештә булган урыннарда күтәрелә.

11 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагы һәм аның сурәте, зурлыгына карамастан, әлеге Законга кушып бирелүче (2 нче кушымта) төсле һәм схематик сурәтләренә төгәл туры килергә тиеш.

12 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагын әлеге Законның 9 статьясындагы 3 пунктында санап үтелгән биналарда тантаналы вакыйга көннәрендә күтәрү, бәйрәм көннәреннән һәм истәлекле көннәрдән гайре, Татарстан

Республикасы Министрлар кабинеты яисә районнарның, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең администрацияләре башлыклары карары буенча башкарыла.

13 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагын әлеге Законда бәян ителгән таләпләрне үтәгән килеш күтәрү һәм урнаштыру вазыйфасы тиешле дәүләт органнарының һәм җәмәгать берләшмәләренең, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә, шулай ук торак-эксплуатация хезмәтләренең җитәкчеләренә йөкләнә.

14 статья. Дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар уздыручы церемонияләрдә һәм башка тантаналы гамәлләр вакытында Татарстан Республикасының Дәүләт флагын күтәрү (урнаштыру) шушы органнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре күрсәтмәсе белән башкарыла.

15 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт флагын башка дәүләтләрнең дәүләт флаглары белән бергә күтәргәндә (урнаштырганда) Татарстан Республикасы Дәүләт флагының зурлыгы башка дәүләтләрнең дәүләт флаглары зурлыгына туры килергә тиеш.

16 статья. Татарстан Республикасы территориясендә матәм игълан ителгәндә Татарстан Республикасының Дәүләт флагы әлеге Законның 9 статьясында күрсәтелгән биналарда һәм башка объектларда күтәрелә, бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт флагының өске өлешенә кара тасма беркетелә, аның озынлыгы флаг тукымасы озынлыгына тигез була. Матәм йөзеннән Татарстан Республикасының Дәүләт флагы тоткасының (мачтасының) яртысына кадәр төшерелергә мөмкин.

17 статья. Җәмәгать берләшмәләренең, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның, башка төзелмәләрнең флаглары Татарстан Республикасының Дәүләт флагын кабатларга тиеш түгел, ул шушы флагларның нигезе сыйфатында да кулланылырга тиеш түгел.

## III бүлек. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны

18 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны

-композитор Рөстәм Яхинның музыкаль әсәреннән гыйбарәт. Татарстан Республикасы Дәүләт гимнының музыкаль редакциясе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасының Дәүләт гимны «Татарстан Республикасының Дәүләт гимны турында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 14 июлендәге карары (3 кушымта) белән расланган гимнның музыкаль редакциясендә төгәл башкарыла.

19 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны дәүләт органнары уздыра торган тантаналы церемонияләр һәм башка төрле гамәлләр вакытында башкарыла:

Татарстан Республикасының Дәүләт флагын күтәргәндә;

яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты ант иткәннән соң;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен ачканда һәм япканда;

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары сессияләрен ачканда һәм япканда;

дәүләтләрнең һәм хөкүмәтләрнең рәсми визит белән Татарстан Республикасына килүче башлыкларын каршы алганда һәм озатып калганда - тиешле дәүләтнең дәүләт гимнын башкарганнан соң;

һәйкәлләр, монументлар, обелисклар һәм Татарстан Республикасы тормышындагы иң мөһим тарихи вакыйгалар хөрмәтенә башка корылмалар ачканда;

Татарстан Республикасының дәүләт бәйрәмнәренә багышланган тантаналы җыелышларны ачканда һәм япканда, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздыра торган башка төрле тантаналы гамәлләр вакытында;

«Татарстан» телерадиотапшырулар компаниясенең радио тапшыруларын башлаганда - һәркөнне.

20 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын мәҗбүри башкаруның башка төрле очраклары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

21 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны Татарстан Республикасы Хөкүмәте, дәүләт органнарының һәм җәмәгать берләшмәләренең, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның

җитәкчеләре карары буенча, әлеге Закон таләпләрен үтәгән килеш, бүтән очракларда да башкарылырга мөмкин.

22 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимнын эчке эшләр органнарында, Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитетында, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хәрби частьләрдә башкару, шулай ук гимн башкарылганда хәрби сәламләүләр, хәрби уставлар, Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты һәм Казан гарнизоны башлыгы тарафыннан билгеләнүче кагыйдәләр белән регламентлана.

23 статья. Татарстан Республикасы гамәлләрне республика территориясеннән читтә уздырганда Татарстан Республикасының Дәүләт гимны халыкара хокук нормалары, дипломатик беркетмә кагыйдәләре һәм шушы ил традицияләренә туры китереп башкарыла.

24 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны оркестр яисә инструменталь башкаруда башкарылырга мөмкин. Бу чакта тавыш яздыру чаралары да кулланылырга мөмкин.

25 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны халык алдында башкарылганда анда катнашучылар гимнны баскан килеш, ирләр исә - баш киемнәрен салып тыңлыйлар.

26 статья. Тиешле гамәлләр уздыручы дәүләт органнарының һәм җәмәгать берләшмәләренең, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре Татарстан Республикасының Дәүләт гимнын башкарганда билгеләнгән таләпләрне үтәргә тиеш.

## IV бүлек. Татарстан Республикасының дәүләт символларына карата халык алдында ихтирамсызлык күрсәткән өчен җаваплылык

27 статья. Татарстан Республикасының Дәүләт гербын яисә Дәүләт флагын мәсхәрәләүче язулар язу, зарарлау, юкка чыгару рәвешендәге гамәлләр аша Татарстан Республикасының Дәүләт гербына яисә Дәүләт флагына карата халык алдында ихтирамсызлык күрсәткән өчен йә Татарстан Республикасының Дәүләт гербын, Дәүләт флагын аларга карата ачыктан-ачык санга сукмауны чагылдырган ысуллар белән файдаланган өчен, -

гражданнарга һәм урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салу рәвешендә административ җаваплылык карала.

Административ җәза бирелгәннән соң бер ел эчендә шундый ук гамәлләр кылган өчен, -

гражданнарга һәм урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең алтыдан алып ун минималь күләменә кадәр штраф салу рәвешендә административ җаваплылык карала.

28 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзеләләр.

29 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда судлар тарафыннан карала.

30 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар өчен штрафлар суммасының 50 проценты хокук бозылган урын буенча районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең бюджетларына, ә 50 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

## V бүлек. Йомгак нигезләмәләр

31 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

32 статья. Әлеге Законны гамәлгә керткән көннән «Татарстан Республикасының Дәүләт гербы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1992 елның 7 февралендәге карары, «Татарстан Республикасының Дәүләт флагы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1991 елның 29 ноябрендәге карары үз көчләрен югалткан, дип танырга.

33 статья. «Татарстан Республикасының Дәүләт гимны турында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 14 июлендәге карарының 3 пункты үз көчен югалткан, дип танырга.

34 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасының дәүләт символларын куллану мәсьәләләре буенча үзенең хокукый актларын әлеге

Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2284

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 655. Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

I. Татарстан Республикасы Конституциясенә (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, №9-10; 1994 ел, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, № 2-3, № 12; 1996 ел, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 66 статьяның алтынчы өлешен төшереп калдырырга.

2 статья. 68 статьяга түбәндәге эчтәлектә өченче өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар башка вакытка күчерелергә мөмкин, әмма ул вакыт дүрт айдан да артмаска тиеш.».

3 статья. 70 статьяның өченче өлешендә «иректән мәхрүм итү урынында тотылган кешеләр» сүзләреннән соң «шулай ук психиатрия хастаханәсендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар» сүзләрен төшереп калдырырга.

4 статья. 72 статьяның беренче өлешенә «Премьер-министрдан кала башка әгъзалары,» сүзләреннән соң «башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территория органнары җитәкчеләре» дигән сүзләрне өстәргә.

5 статья. 76 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«76 статья. Эш (уку, хезмәт итү) урыны һәм яшәү урыны буенча сайлаучылар җыелышлары, үзен үзе күрсәтү тәртибендә сайлаучылар, шулай ук законда билгеләнгән

тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары халык депутатына кандидатлар күрсәтү хокукына ия булалар.».

6 статья. 78 статьяның соңгы җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлау комиссияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе закон белән билгеләнә.».

7 статья. 79 статьяга «гарантияләнә» сүзе алдыннан «закон нигезендә» дигән сүзләрне өстәргә.

8 статья. 81 статьяның беренче өлешендә «бәхәсләрне» сүзеннән соң «югарырак сайлау комиссияләре йә» дигән сүзләрне өстәргә.

9 статья. 89 статьяның икенче өлешендәге 22 пунктында «Татарстан Республикасы Үзәк референдум комиссиясе составын раслау» сүзләрен төшереп калдырырга.

10 статья. 89 статьяның икенче өлешендәге 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау;».

11 статья. 89 статьяның өченче өлешендә түбәндәге эчтәлектә 18 нче пункт өстәргә:

«18) Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау.».

12 статья. 92 статьяның икенче өлешендә «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

13 статья. 94 статьяга «Татарстан Республикасы Прокуроры» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе» дигән сүзләрне өстәргә.

14 статья. 101 статьяның беренче өлешендәге 2 пунктында «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

15 статья. 111 статьяның 7 пунктындагы «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2304

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 656. «Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

I. «Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994 ел, № 11, 136 статья) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. Статья ахырына түбәндәге җөмләне өстәргә:

«Татарстан Республикасы халык депутатының сайлауларда катнашуы ирекле һәм ихтыярый була. Сайлауларда катнашуга яисә катнашмауга мәҗбүр итү максатында Татарстан Республикасы гражданына йогынты ясарга, шулай ук аның ихтыярын ирекле белдерүенә каршылык күрсәтергә беркем дә хокуклы түгел.».

2 статья. 2 статьяның 3 пунктында «шулай ук психиатрия хастаханәләрендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар» сүзләрен төшереп калдырырга.

3 статья. 3 статьяда:

2 пунктны 3 пункт дип санарга;

3 статьяга түбәндәге эчтәлектә 2 пункт өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлаулар башка вакытка күчерелергә мөмкин, ләкин ул вакыт дүрт айдан да артмаска тиеш.».

4 статья. 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халык депутатына кандидатларны күрсәтү хокукына түбәндәгеләр ия:

сайлаучыларның эш (уку, хезмәт) һәм яшәү урыны буенча җыелышлары;

үзен үзе күрсәтү тәртибендә сайлаучылар үзләре;

законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары.

Сайлауларның дәрәҗәсенә туры килгән дәрәҗәдә законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сәяси-иҗтимагый берләшмәләр исемлеге, сайлаулар көне игълан ителгәч 7 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк

сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан тапшырыла.

Затның сайланырга риза булуы хакында язмача гаризасы булганда кандидат булып күрсәтелергә мөмкин, әлеге гаризада исә кандидатның биографик характердагы белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, ае, елы, белеме, төп эш яки хезмәт урыны (төп эш яки хезмәт урыны булмаган очракта - шөгыленең төре), биләгән эш урыны, Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез итеп алынган статьясының (статьяларының) номерын (номерларын), исемен (исемнәрен) күрсәтеп, кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүләре турындагы белешмәләр, шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзының һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит дәүләт законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелә, гражданлыгы күрсәтелә (шул исәптән датасын һәм аны алу өчен нигез булып хезмәт иткән хәлләрне кертеп), чит дәүләт гражданлыгы күрсәтелә, һәм, Россия Федерациясе Дәүләт Думасына да сайлаулар бер үк вакытта уздырылганда, фәкать бер сайлау округында гына тавышка куелачагы, ә сайланган очракта - депутат статусына туры килмәслек эшчәнлеген туктатачагы яки сайлап куелучы башка эш урынында эшләмәячәге хакында йөкләмә тапшырыла. Күрсәтелгән гариза, имзалар җыя башлау хакындагы хәбәрнамә белән бергә, тиешле сайлау комиссиясенә җибәрелә.».

5 статья. 8 статьяда:

3 пункттагы соңгы җөмләне төшереп калдырырга;

4 пунктны 6 пункт дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 4 пунктны өстәргә:

«4. Вәкилләр һәм күзәтүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

а) сайлаучылар исемлеге белән танышырга;

б) тавыш бирү көнендә тиешле сайлау участогында тавыш бирү бинасында булырга;

в) тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргәндә катнашырга;

г) сайлаучылар исемлегенә кертелгән гражданнарны, сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәрен, юкка

чыгарылган сайлау бюллетеньнәрен исәпләп чыгаруны күзәтергә; тавыш бирү бюллетеньнәре үзләренә күренерлек ераклыкта һәм шартларда сайлаучыларның сайлау участогында тавышларын санауны күзәтергә; сайлаучыларның тавышларын санаганда теләсә кайсы тутырылган яисә тутырылмаган сайлау бюллетене белән танышырга; тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясенең беркетмә һәм башка документлар төзүен күзәтергә;

д) тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белән - сайлау комиссиясе рәисенә, ул булмаганда - аны алыштыручы затка мөрәҗәгать итәргә;

е) тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясе беркетмәсе белән, шулай ук башка сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары һәм сайлауларның нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән танышырга; тиешле сайлау комиссиясеннән күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән документларның, шулай ук тиешле сайлау комиссияләренә кергән башка документларның күчермәләрен дә, шул исәптән тавыш бирүдә катнашкан затларның исемлеген дә әзерләтергә яисә соратып алырга. Күзәтүче таләбе буенча сайлау комиссиясе күрсәтелгән күчермәләрне бирергә яисә таныкларга тиеш;

ж) участок сайлау комиссиясенең, башка төрле сайлау комиссиясенең гамәлләре (гамәл кылмаулары) хакында югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка мөрәҗәгать итәргә;

з) тиешле комиссияләрдә сайлаучыларның тавышларын кабат санаганда катнашырга.»;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 5 пунктны өстәргә:

«5. Сайлау комиссиясе утырышларында тавыш бирүдә һәм сайлау нәтиҗәләренә йомгак ясауда катнашучы вәкилләр һәм күзәтүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

а) сайлаучыларга сайлау бюллетеньнәре һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирергә;

б) сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетенен һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын алган өчен аның урынына имза салырга;

в) сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетенен тутырырга;

г)тавыш бирү серен бозарлык башка гамәлләр кылырга;

д) сайлау комиссияләре әгъзалары сайлау

бюллетеньнәрен санаганда катнашырга;

е) сайлау комиссиясе эшенә комачаулык итәрлек гамәлләр кылырга;

ж) сайлаучылар арасында үгетләү эшләре алып барырга;

з) тиешле сайлау комиссиясе карар кабул иткәндә катнашырга.».

6 статья. 6,9,11,12,13,14 статьяларның исемнәрендә һәм текстында, үзәк, округ һәм участок сайлау комиссияләренең исемнәрендәге «халык депутатларын сайлаулар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

7 статья. 11 статьяда:

4 пунктта «Исемлеккә участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала» дигән сүзләрне «сайлаучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә, исемлеккә участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала һәм ул участок сайлау комиссиясе мөһере белән таныклана» дигән сүзләр белән алыштырырга;

5 пунктта «ике көннән дә соңга калмыйча, ә сайлаулар алдыннан һәм» дигән сүзләрне төшереп калдырып, «24 сәгать эчендә» дигән сүзләр өстәргә, «сайлауларга кадәр биш көннән дә соңга калмыйча» дигән сүзләрне төшереп калдырырга, «өч көн эчендә» сүзләреннән соң өтер куярга һәм «ә тавыш биргән көнне кичекмәстән» дигән сүзләр өстәргә;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 7 пунктны өстәргә:

«7. Тавыш бирү тәмамланганнан һәм сайлаучыларның тавышларын саный башлаганнан соң сайлаучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәреш кертү тыела.».

8 статья. 13 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлауларга кадәр 90 көннән дә соңга калмыйча, комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм комиссиянең 12 әгъзасы составында барлыкка китерелә.»;

13 статьяның 3 пунктында «Президенты» дигән сүздән соң түбәндәге эчтәлектә сүзләр өстәргә: «сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының, иҗтимагый берләшмәләрнең, сайлаучыларның эш, хезмәт, уку, яшәү урыны буенча җыелышларының, Үзәк сайлау комиссиясенең элек-

кеге составы тәкъдимнәрен исәпкә алып».

9 статья. 14 статья текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә».

10 статья. 15 статьяга түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Округ сайлау комиссияләре иҗтимагый берләшмәләр, сайлаучыларның эш, хезмәт, уку, яшәү урыны буенча җыелышлары тәкъдимнәрен исәпкә алып барлыкка китерелә.».

11 статья. 16 статьяга түбәндәге өстәмәне кертергә:

1 пунктның «е» пунктчасына «тавыш бирү өчен сайлаучыларга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирә»;

түбәндәге эчтәлектә 3 пунктны өстәргә:

«Административ-территория округларының округ сайлау комиссияләре вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре башкара.».

12 статья. 17 статьяга «калмыйча,» сүзеннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә: «иҗтимагый берләшмәләр, сайлаучыларның эш, хезмәт, уку, яшәү урыны буенча җыелышлары тәкъдимнәре нигезендә».

13 статья. 18 статьяның 1 пунктындагы «д» пунктчасына түбәндәге сүзләрне өстәргә: «сайлаучыларга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирә».

14 статья. Түбәндәге эчтәлектә $18^1$ статьясын кертергә:

«**$18^1$ статья.** Сайлау комиссияләре әгъзаларының статусы

Депутатлар, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының урындагы сайлаулы затлары, судьялар, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатларны тәкъдим иткән сайлаучылар җыелышларының һәм сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары, сайлау комиссияләренең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, кандидатларның, теркәлгән кандидатларның ирләре

йә хатыннары һәм якын туганнары яисә кандидатларның, теркәлгән кандидатларның турыдан-туры буйсынуындагы затлар комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары була алмыйлар.

Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлау комиссиясенең барлык утырышларында катнашырга тиеш.

Сайлау комиссиясе әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

тиешле сайлау комиссиясе утырышлары хакында алдан хәбәр алырга;

сайлау комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле сайлау комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирү уздыруны таләп итәргә;

сайлау комиссиясе утырышындагы башка катнашучыларга көн тәртибе нигезендә сораулар бирергә һәм аларга төпле җаваплар алырга;

теләсә кайсы документлар һәм материаллар (шул исәптән, тиешле һәм түбәнгерәк сайлау комиссияләренең машинадан укыла торган саклагычлардагы документларны һәм материалларны да кертеп, сайлаучылар исемлекләре, сайлау бюллетеньнәре) һәм аларның (сайлаучылар исемлекләреннән, сайлау бюллетеньнәреннән тыш) күчермәләрен алырга һәм бу күчермәләрне таныклауны таләп итәргә.

Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы аны билгеләп куйган органның карары белән вәкаләтләр чоры тәмамланганчы ук сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан түбәндәге очракларда азат ителергә мөмкин:

сайлау комиссиясе әгъзасының вәкаләтләрен үз өстеннән төшерүе хакындагы язмача гаризасы булганда;

Татарстан Республикасыннан даими яшәү урынына күчеп киткәндә;

сайлау комиссиясе әгъзасына карата судның гаепләүче хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип, кайдалыгы билгесез яисә вафат булган дип танылганда;

Татарстан Республикасы гражданлыгын югалтканда;

сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларын даими

үтәмәгәндә - сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча;

әлеге Законда каралган бүтән төрле нигезләр булганда.

Бер үк вакытта республика һәм федераль сайлаулар уздырылган очракта, округ һәм участок сайлау комиссияләренең төп эшләреннән азат ителгән рәисенә һәм секретарена сайлауларга кадәр 60 көн кала сайлаулар уздыру өчен бүлеп бирелгән Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары исәбеннән ай саен хезмәт өчен түләү башкарыла, аның күләме җиде минималь хезмәт хакы күләменнән артык булмаска тиеш. Сайлауларны әзерләү һәм уздыру чорына сайлау комиссиясенең төп эшләреннән азат ителгән башка әгъзаларына хезмәт өчен түләү сайлаулар уздыруга бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла, аның күләме төп эш урыны буенча уртача хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш.

Үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчы сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы администрация (эш бирүче) инициативасы белән эшеннән азат ителә алмый яисә комиссия әгъзасының ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый.

Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлаулар уздыру чорында Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына яки суд тәртибендә билгеләнә торган административ җәза гамәлләренә тартыла алмый.

Сайлау комиссиясе тарафыннан кандидат теркәлгәннән соң, әлеге кандидат үзен теркәгән сайлау комиссиясенә һәм түбәнгерәк сайлау комиссиясенә киңәш бирү тавышы хокукына ия берәр әгъза билгеләп куярга хокуклы.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы бер үк вакытта бүтән төрле сайлау комиссиясе әгъзасы була алмый.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы сайлауларны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләре буенча комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының бөтен хокукларына да тулаем ия була.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары, сайлау бюллетеньнәре бирергә;

сайлау бюллетеньнәрен сортировкалауда һәм санауда катнашырга;

табыш бирү йомгаклары һәм сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә төзүдә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларын кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларына имза салырга.».

15 статья. 19 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау комиссиясенең карарлары ачык яки яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Сайлау комиссиясе рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлау турында, халык депутатына кандидатларны теркәү турында, сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү турында, сайлауларны узмаган яки гамәлгә яраксыз дип тану турында, кабат тавыш бирү яисә кабат сайлаулар уздыру турында сайлау комиссиясе карарлары тиешле сайлау комиссиясе утырышында, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

Сайлау комиссияләренең башка төрле мәсьәләләр буенча карарлары сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Сайлау комиссияләре карарлар кабул иткәндә хуплап һәм каршы бирелгән тавышлар саны тигез булса, сайлау комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Сайлау комиссиясе карарларына сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала.

Сайлау комиссиясе кабул иткән карар белән килешмәгән сайлау комиссиясе әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язмача белдерергә хокуклы, бу фикер, өч көннән дә соңга калмыйча, ә сайлауларга өч көн кала һәм сайлаулар көнендә кичекмәстән сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан югарырак сайлау комиссиясенә җиткерелергә тиеш.

Сайлау комиссиясенең законны бозган килеш кабул иткән карары югарырак сайлау комиссиясе яки суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш.

19 статьяның 7 пунктын төшереп калдырырга, 8,9,10

пунктларны 7,8,9 пунктлар дип санарга.

16 статья. IV бүлекнең исемендә «күрсәтү» сүзеннән соң «һәм теркәү» сүзләрен өстәргә.

17 статья. 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. Халык депутаты статусының вазыйфаи хәленә туры килмәве

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре һәм, Премьер-министрдан кала, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының башка әгъзалары, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территория органнары җитәкчеләре, шулай ук судьялар депутат була алмыйлар.».

18 статья. 21 статьяда:

3 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халык депутатына кандидатларны сайлаучылар турыдан-туры үзен үзе күрсәтү юлы белән, шулай ук сайлаучыларның эш (уку, хезмәт) һәм яшәү урыны буенча җыелышлары, законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары күрсәтә ала. Кандидатны күрсәтү хакында кандидат теркәләчәк тиешле округ сайлау комиссиясенә хәбәр ителә. Кандидатларның үз-үзләрен күрсәтүе тулы биографик хәле турындагы белешмәләре белән һәм үзен хуплап җыелган имзалар турындагы хәбәре белән бергә тиешле сайлау комиссиясенә язма гариза бирү рәвешендә башкарыла.»;

3 пункттагы 2 абзацта «фиркаләрнең, һөнәр берлекләренең һәм башка» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

3 пунктта 3,4,5 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары һәр сайлау округында халык депутатына берәр кандидат күрсәтергә хокуклы.

Сайлаучылар җыелышларында һәм сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары карарлар кабул иткәндә чикләнмәгән сандагы кандидатуралар буенча фикер алышулар өчен шартлар тудырыла. Сайлаучылар җыелышында һәр катнашучы, сайлау

берләшмәсе, сайлау блогы әгъзасы халык депутатына кандидатлар хакында тәкъдимнәр кертергә, алар турында фикер алышуларда катнашырга, тәкъдим ителгән кандидатураларны хупларга йә аларны кире кагу хакында тәкъдимнәр кертергә, халык депутатына кандидат сыйфатында фикер алышулар өчен үз кандидатурасын тәкъдим итәргә хокуклы. Халык депутатына кандидат күрсәтү турындагы карар ачык яисә яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү тәртибе һәм башка процедура мәсьәләләре сайлаучылар җыелышында билгеләнәләр. Сайлаучылар җыелышында катнашучыларның яртысыннан артыграгы халык депутатына кандидат өчен тавыш бирсә, ул күрсәтелгән дип санала. Сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары халык депутатына кандидат күрсәтү хакындагы карарны үзләрен гамәлгә кую документларында билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр. Халык депутатына кандидат күрсәтү хакында беркетмә төзелә. Кабул ителгән карар турында ике көннән дә соңга калмыйча халык депутатына кандидатка хәбәр ителә.».

4 пунктка түбәндәге җөмләне өстәргә:

«Кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, имзалар кәгазендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит дәүләт законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, имзалар кәгазендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.»;

5 пункттагы беренче абзацта беренче җөмләдән соң түбәндәгеләрне кертергә:

«Кандидатны хуплап имза салучы сайлаучылар турындагы белешмәләр кандидатны хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан имзалар кәгазенә кертелергә мөмкин.». Абзац азагында түбәндәгеләрне өстәргә: «Күрсәтелгән белешмәләр бары тик кулдан язып кертеләләр».

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Административ-территория сайлау округлары буенча

халык депутатына кандидатлар итеп шушы сайлау округы территориясендә даими яшәүче яки эшләүче Татарстан Республикасы гражданнары күрсәтеләләр.»;

9 пунктка түбәндәге җөмләне өстәргә: «Бу чакта сайлаучылар үзләре кандидатны күрсәткән шушы округ территориясендә эшләсәләр яки яшәсәләр, сайлаучылардан кандидат күрсәтү хокукый тәгаенләнгән була».

19 статья. 22 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Кандидатларны теркәү өчен округ сайлау комиссиясенә кандидатның шулай ук милек хокукындагы керемнәре һәм мөлкәте хакында белешмәләр тапшырылырга тиеш. Керемнәренең күләме һәм чыганаклары хакындагы белешмәләр, кандидат булган гражданның сайлаулар билгеләнгән елга кадәр узган ел өчен керемнәре турындагы декларациянең күчермәсе рәвешендә (салым органнары тамгасы белән) тапшырыла. Кандидат булган граждан салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә керемнәре хакында декларация бирергә тиеш булмаган очракта, керемнәр алынган урын буенча оешмадан сайлаулар билгеләнгән елга кадәр узган ел өчен аның тулаем керемнәре хакындагы белешмә тапшырыла. Кандидатның милек хокукындагы мөлкәте турындагы белешмәләр әлеге Закон кушымтасында билгеләнгән рәвештә тапшырыла.

Округ сайлау комиссиясе әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турындагы тәкъдим белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

8,9 пунктларны 9,10 пунктлар дип санарга;

статьяга түбәндәге редакциядә 8 пунктны өстәргә:

«8. Әгәр калган имзалар саны әлеге Закон таләпләре нигезендә теркәлү өчен билгеләнгән саннан кимрәк булса, имза салу кәгазьләрендә дөрес булмаган имзалар ачылганда халык депутатына кандидатның теркәлүе суд тәртибендә юкка чыгарыла.».

20 статья. 23 статьяда:

5 пунктны төшереп калдырырга;

6,7,8,9,10 пунктларны 5,6,7,8,9 пунктлар дип санарга.

21 статья. 25 статьяда:

1 пунктка «сайлау берләшмәләренә» дигән сүзләрдән

соң «сайлау блокларына» дигән сүзләрне өстәргә;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау комиссияләре әгъзаларына сайлау алды үгетләве уздыру, теләсә нинди сайлау алды үгетләве материалларын тарату, шулай ук сайлау комиссияләре биналарында һәм тавыш бирү биналарында да, тыела.

Сайлаучыларга бушлай яки ташламалы шартларда товарлар сату, хезмәт күрсәтү (мәгълүмат хезмәте күрсәтүдән кала), кыйммәтле кәгазьләр сату, шулай ук акча өләшү юлы белән сайлау алды үгетләве алып бару тыела.».

22 статья. 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үгетләү кампаниясе кандидатны теркәгән көннән уздырыла башлый һәм сайлаулар көне алдыннан 0 сәгатьтә туктатыла. Сайлаулар көне алдындагы көн дәвамында һәм тавыш бирү көнендә теләсә нинди сайлау алды үгетләве тыела.».

23 статья. 29 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү бинасында яисә аның каршында ук стенд җиһазлый, анда шушы округ буенча теркәлгән барлык кандидатлар хакында мәгълүмати материаллар урнаштырыла. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, мәгълүмати материалларда Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) номеры (номерлары) һәм исеме (исемнәре), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, мәгълүмати материалларда тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш. Тутырылган сайлау бюллетеньнәре үрнәкләре стендка урнаштырыла, аларда шушы сайлау округында теркәлгән кандидатларның фамилияләре булмаска тиеш. Мәгълүмати материалларда үгетләү өндәмәләре булмаска тиеш.».

24 статья. 30 статьяда:

1 пунктта «12» цифрын «20» гә, «ике» сүзен «дүрт» сүзенә алыштырырга;

1 пунктның соңгы җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлау бюллетененең алгы ягындагы өстәге уң як почмагына участок комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар участок комиссиясе мөһере белән таныклаыналар».

30 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Уң якта һәр кандидат турындагы белешмәләр каршысына буш квадрат урнаштырыла. Кандидатлар исемлеге ахырында «Барлык кандидатларга каршы» дигән юл урнаштырыла һәм ул әлеге юлның уң ягындагы буш квадрат каршысында була. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, сайлау бюллетенендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, сайлау бюллетенендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.».

25 статья. Законга түбәндәге редакциядә $30^1$ статья өстәргә:

«$30^1$ статья. Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы

1. Сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы тиешле округ сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 45-25 көн кала) йә шушы сайлау участогының участок сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 24-1 көн кала) бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, тавыш бирү көнендә кайсы сайлау участогында булса, шунда, үзе актив сайлау хокукына ия булган сайлау округы чикләрендә тавыш бирүдә катнашырга

хокуклы.

2. Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы катгый хисап документы була, аның яклану дәрәҗәсен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләү һәм бирү рәвеше, тәртибе, аларны бирү саны һәм реестр рәвеше, шулай ук аларны әзерләүгә карата куелучы таләпләр Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирергә 60 көннән дә соңга калмыйча расланалар. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары югарырак сайлау комиссиясеннән түбәнгерәк сайлау комиссиясенә сайлау бюллетеньнәрен бирү тәртибендә тапшырылалар. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыручы, алучы һәм саклаучы сайлау комиссияләре рәисләре бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшырган өчен һәм аларның сакланышы өчен җаваплы булалар.

3. Тиешле сайлау комиссиясе сайлаучының бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын таләп итүнең сәбәбен күрсәтеп язган гаризасы нигезендә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын сайлаучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук сайлаучы дәваланучы стационар дәвалау-профилактика учреждениесе администрациясе тарафыннан да, шик белдерелүче яисә гаепләнүче затны сак астында тотучы учреждение администрациясе тарафыннан да таныкланырга мөмкин.

Администрация башлыгы тарафыннан сайлаучылар турында комиссиягә бирелгән белешмәләр нигезендә округ сайлау комиссиясе сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын тапшыра. Округ сайлау комиссиясе бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрын төзи, анда сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Тавыш бирергә 25 көн кала округ сайлау комиссиясе участок сайлау комиссиясенә, сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне

җибәрә, тиешле сайлау участоклары территорияләрендә теркәлгән һәм аларда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары алган сайлаучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Шундый өземтә нигезендә участок сайлау комиссиясе сайлаучылар исемлегенә тиешле тамгаларны кертә.

4. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алуы турында сайлаучы яисә аның вәкиле бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына (округ сайлау комиссиясендә) йә сайлаучылар исемлегенә (участок сайлау комиссиясендә) имза салалар, анда паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

Бу чакта шушы сайлаучы әлеге сайлаулардагы тиешле участок сайлаучылары исемлегеннән төшереп калдырыла һәм участок сайлау комиссиясенең беркетмәсен төзегәндә теркәлгән сайлаучыларның санын санаганда исәпкә алынмый.

5. Әгәр бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгында округ яисә участок сайлау комиссиясенең мөһере һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән округ яисә участок сайлау комиссиясе әгъзасының имзасы булса, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы гамәлгә яраклы дип санала.

6. Тавыш бирү көнендә сайлаучы, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәтеп, үзе актив сайлау хокукына ия булган сайлау округы чикләрендәге теләсә кайсы башка сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә тиеш, шуннан соң бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы аңардан кире алына. Бу чакта сайлаучы сайлау бюллетене (сайлау бюллетеньнәре) алганнан соң сайлаучылар исемлегендә өстәмә рәвештә үзе яшәгән урынның адресын күрсәтә.

7. Тавыш бирү көнендә сайлаучы элек сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогында ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткән очракта, сайлаучы өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә, ә аның бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы аңардан кире алына һәм юкка чыгарыла.

8. Тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары юкка чыгарыла, бу турыда тиешле округ яисә

участок сайлау комиссиясе акт төзи.».

26 статья. 31 статьяда:

беренче җөмләдә «үткәрелә» сүзеннән соң «Татарстан Респуб-ликасы Дәүләт Советы карары буенча тавыш бирүнең башка вакыты билгеләнергә мөмкин» дигән сүзләр язарга;

1 пунктта «10» цифрын «20» гә алыштырырга;

3 пунктны төшереп калдырырга;

4 пунктта икенче һәм өченче җөмләләрне төшереп калдырырга;

6 пунктта «яисә күзәтүчедән» сүзләрен «теркәлгән кандидатлардан, ышанычлы затлардан, күзәтүчеләрдән һәм вәкилләрдән» дигән сүзләр белән алыштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.Сайлау бюллетеньнәрендә сайлаучы үзе тавыш биргән кандидат фамилиясенең каршысындагы буш квадратка йә «Барлык кандидатларга каршы» дигән юлдагы квадратка теләсә нинди тамга сала.»;

9 пунктта «икедән дә күп» дигән сүзләрне «өчтән дә артыграк» дип алыштырырга;

4,5,6,7,8,9 пунктларны 3,4,5,6,7,8 пунктлар дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 9 пунктны өстәргә:

«9. Әгәр участок сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирүнең яшеренлеген бозсалар яисә сайлаучыга үз ихтыярын белдерергә комачаулык итәргә маташсалар, участок сайлау комиссиясе әгъзасы комиссия эшеннән кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарылалар. Бу хакта участок сайлау комиссиясе тарафыннан карар кабул ителә.».

27 статья. Түбәндәге эчтәлектә $31^1$ статья кертергә:

«**$31^1$ статья.** Тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясе беркетмәсе

1. Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) нөсхәнең номеры;

б) сайлауларның исеме, тавыш бирү датасы, сайлау округының исеме һәм номеры;

в) «Беркетмә» сүзе;

г) сайлау участогының номеры күрсәтелгән килеш, сайлау комиссиясенең исеме;

д) беркетмә юллары:

1 юл. Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре саны;

3 юл. Юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре саны;

4 юл. Тавыш бирү көнендә сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

5 юл. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

6 юл. Күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

7 юл. Стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

8 юл. Гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре саны;

9 юл. Гамәлгә яраксыз, шул исәптән кайбер юллары буенча гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәренең гомуми саны;

10 юл. Тиешле сайлау округы буенча тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләреннән алынган сайлау бюллетеньнәренең саны сайлаучыларның сайлау бюллетеньнәрен алулары турында тамга куелган гаризалары санынннан артып киткәндә, гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау бюллетеньнәре саны;

11 юл. Бер позиция буенча да тамгасы булмаган яисә бердән артыграк позициядә тамгалары булган гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәре саны;

12 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юл. Сайлау участогында тавыш бирү көненә кадәр участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юл. Сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

15 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмыйча юкка чыгарылган таныклыклары саны;

16 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү әлеге Законның 30[1] статьясындагы 7 пункты нигезендә юкка чыгарылган таныклыклары саны;

е) беркетмәгә кушымта итеп бирелүче шикаятьләр (гаризалар), актлар һәм башка документлар исемлеге;

ж) сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретаренең һәм башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары, аларның имзалары;

з) беркетмәгә имза салынган дата һәм вакыт (сәгатьләре һәм минутлары) (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен);

и) сайлау комиссиясенең мөһере (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен).

2. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 17 нче юлына һәм аннан соңгы юлларына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр языла:

теркәлгән кандидатларның алфавит тәртибендә фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алар бер-берсенә тәңгәл килгәндә - теркәлгән кандидатлар турында сайлау бюллетененә кертелгән бүтән белешмәләр һәм теркәлгән һәр кандидат өчен сайлаучылар тарафыннан бирелгән тавышлар саны;

сайлаучылар тарафыннан кандидатларның барысына да каршы бирелгән тавышлар саны.

3. Әлеге статьяның 1-2 пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә цифрлап һәм язмача кертелә.».

28 статья. 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**32 статья.** Сайлау участогында тавышларны санау тәртибе

1. Тавыш бирү вакыты беткәч, участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирүнең тәмамлануы хакында игълан итә.

2. Тавышларны санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен саныйлар, юкка чыгаралар, аннары аларның санын игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 3 юлына язып куялар. Юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре санына шулай ук тавыш биргәндә сайлаучылар тарафыннан бозылган сайлау бюллетеньнәре дә керә.

Шуннан соң участок сайлау комиссиясе әгъзалары бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларының санын игълан итәләр һәм тавыш бирү

йомгаклары турындагы беркетмәнең 15 юлына язып куялар.

Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең әлеге Законның 30[1] статьясындагы 7 пункты нигезендә юкка чыгарылган таныклыклары санала, аларның саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 16 юлына язып куела.

3. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

а) округ һәм участок комиссияләрендә тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирелгән сайлаучыларны исәпкә алмыйча, исемлеккә кертелгән сайлаучылар санын;

б) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә бирелгән сайлау бюллетеньнәре санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалар саны буенча билгеләнә);

в) сайлаучыларга тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

г) сайлаучыларга участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары санын;

д) сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар санын.

4. Шушы күрсәткечләр кертелгәннән соң сайлаучылар исемлегенең һәр битенә участок комиссиясенең әлеге күрсәткечләрне керткән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, аннары ул күрсәткечләр сайлаучылар исемлеге буенча тулаем кушып берләштерелә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертелә, участок сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының яки секретаренең имзалары һәм мөһер белән таныклана. Һәр бит һәм исемлек буенча йомгаклар тулысынча игълан ителә.

5. Участок сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре түбәндәгеләрне ачыклыйлар һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 1 һәм 2 юлларына кертәләр:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын;

б) участок комиссиясе алган сайлау бюллетеньнәре санын.

6. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

12 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юлга - бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча сайлау участогында тавыш биргән сайлаучылар саны.

7. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

4 юлга - тавыш бирү көнендә сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юлга - тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

8. Бу гамәлләрдән соң участок сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре сайлаучылар исемлеген тавышларны санауда катнашучы затлар файдаланмаслык итеп саклауны тәэмин итәргә тиешләр. Сайлаучылар исемлеге белән алга таба эш итү бары тик тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары тикшерелгәннән соң гына әлеге статьяның 15 пункты нигезендә башкарылырга мөмкин.

9. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирү әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәр буенча сайлаучыларның тавышларын санарга турыдан-туры керешәләр.

Санарга керешкәнче, участок комиссиясе рәисе сайлау әрҗәләрендәге мөһерләрнең яисә пломбаларның бөтенлеген тикшерә һәм аларны ача. Сайлау әрҗәләрен ачу түбәндәге чиратта гамәлгә ашырыла: башта - күчерелмә сайлау әрҗәләре, аннары стационар сайлау әрҗәләре ачыла.

10. Башта күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре санала. Аларның саны игълан ителә һәм беркетмәнең 6 юлына язып куела һәм ул сайлаучыларның

тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалары санынннан артмаска тиеш.

Күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге бюллетеньнәр санының күрсәтелгән гаризалар санынннан артып китүе ачыкланган очракта, күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге барлык сайлау бюллетеньнәре участок сайлау комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип танылалар.

Бу факт, участок комиссиясенең тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелеп, аерым актта чагылдырыла, ул акт тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.

Бу очракта гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр саны беркетмәнең 9,10 юлларына кертелә.

11. Аннары стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны санала һәм беркетмәнең 7 юлына язып куела.

12. Сайлаучыларның тавышларын санаганда, иң элек билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр, ягъни рәсми эшләнмәгән яисә сайлау комиссиясе тарафыннан таныкланмаган бюллетеньнәр һәм гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәре аерып алына. Бу бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

13. Сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерүләрен төгәл ачыклап булмый торган сайлау бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дип санала, мондыйларга түбәндәгеләр керә:

бердән артык квадратка билге куелган бюллетеньнәр;

квадратларның берсенә дә билге куелмаган бюллетеньнәр.

Шикләнүләр туган очракта, участок сайлау комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә. Бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тану турында карар кабул иткәндә, сайлау комиссиясе аның арткы ягында гамәлгә яраксызлыгының сәбәпләрен күрсәтә. Бу язу участок комиссиясе рәисенең һәм секретареның имзалары белән таныклана. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр башка сайлау бюллетеньнәреннән аерым җыеп тотырыла.

Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең саны 9,11 юлларга кертелә.

14. Участок комиссиясе әгъзалары беркетмәнең 8 юлына гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәренең санын язып куялар.

15. Сайлау бюллетеньнәрен санаганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары (4 нче кушымта) тикшерелә. Алар тәңгәл килмәгән очракта, участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юлларын кабат санау турында карар кабул итә. Кабат санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәрешләр кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла.

16. Санаганнан соң - теркәлгән кандидатлар буенча сайлау бюллетеньнәре аерым капларга, барлык кандидатларга каршы тавыш бирелгән бюллетеньнәр - аерым, шулай ук гамәлгә яраксыз һәм юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре дә аерым капларга тутырыла, һәр капта андагы сайлау бюллетеньнәренең саны, теркәлгән кандидатларның фамилияләре күрсәтелә. Шулай тупланган сайлау бюллетеньнәре капчыкларга яисә аерым тартмаларга салына, аларда сайлау участогының, округының үз номеры (исеме), сайлау бюллетеньнәренең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга пломба салып, мөһер сугыла һәм алар бары тик югарырак сайлау комиссиясе яисә суд карары белән генә ачылырга мөмкин.

17. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә өч нөсхәдә тутырыла һәм аларга участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда имза салынган дата һәм вакыт (сәгате, минуты) куела.

18. Беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәгән участок комиссиясе әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерләрен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

19. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

20. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, тиешле законның бозылуына карата участок сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар), шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлеп куела. Әлеге документларның таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

21. Беркетмәнең беренче нөсхәсе кичекмәстән округ

сайлау комиссиясенә җибәрелә.

22. Беркетмәнең икенче нөсхәсе, пломба салып мөһерләнгән сайлау документлары белән бергә, сайлау бюллетеньнәрен һәм мөһерне дә кертеп, сакланучан бинада, пломба салып мөһерләнгән килеш, участок сайлау комиссиясенең эше тәмамлаганчы участок сайлау комиссиясе секретаренда саклана һәм сайлау йомгакларын рәсми игълан иткәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча тиешле округ сайлау комиссиясенә тапшырыла.

23. Беркетмәнең өченче нөсхәсе участок сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында гомуми танышу өчен эленеп куела.».

29 статья. 33 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33 статья. Сайлау округында сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү

1. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләр нигезендә тиешле округ сайлау комиссиясе, аларның дөрес төзелүен алдан тикшергәннән соң, тавыш биргәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча, алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрендәге күрсәткечләрне кушып берләштерүне округ сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үзләре башкаралар.

2. Округ сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлауларны түбәндәге очракларда узмаган дип таный:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның 35 процентыннан кимрәге сайлауларда катнашканда (сайлауларда катнашкан сайлаучыларның саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 4,5 юлларындагы саннарның суммасы белән билгеләнә);

б) бүтән кандидатка (бүтән кандидатларга) караганда иң күп тавыш җыйган кандидат өчен бирелгән сайлаучылар тавышларының саны барлык кандидатларга каршы бирелгән сайлаучылар тавышлары санынннан кимрәк булганда;

в) сайлау округы буенча халык депутатына бер генә кандидат теркәлеп, ул да кандидатлыктан төшеп калганда.

3. Округ сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлаулар нәтиҗәләрен түбәндәге очракларда гамәлгә яраксыз дип таный:

а) тавыш бирүне уздырганда яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә әлеге Законны бозу сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәгәндә;

б) сайлау округы буенча тавыш бирү йомгаклары гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау участокларының саны шушы сайлау округы территориясендә оештырылган сайлау участокларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил иткәндә;

в) суд карары буенча.

4. Әлеге Законны, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмый калган теркәлгән кандидатларның сайлануына ярдәм итәрлек итеп, йә тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмый калган теркәлгән кандидатлар өчен сайлаучыларны тавыш бирергә мәҗбүр итү максаты белән яисә мәҗбүр итеп бозу сайлауларны гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.

5. Округ сайлау комиссиясе тиешле участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре нигезендә сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, аңа түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

а) сайлау округындагы участок сайлау комиссияләренең саны;

б) участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре саны, аларга нигезләнеп әлеге беркетмә төзелә;

в) участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендә булган барлык юллар буенча сайлау округының суммар күрсәткечләре;

г) депутат булып сайланган теркәлгән кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме.

6. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының 50 проценттан күбрәген җыйган теркәлгән кандидат сайлау округы буенча сайланган дип таныла. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның тавышлары саны тавыш бирү әрҗәләреннән алынган мәгълүм рәвештәге сайлау бюллетеньнәре саны буенча билгеләнә.

7. Округ сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсе өч нөсхәдә төзелә, аңа округ сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда аны төзү датасы һәм вакыты (сәгате һәм минуты) күрсәтелә һәм алар мөһер белән таныклана. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә түбәндәгеләр теркәлеп куела:

а) сайлау округы буенча сайлаулар нәтиҗәләре турында җыелма таблица, аңа тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләреннән алынган барлык беркетмәләрнең күрсәткечләре тулаем кертелә;

б) округ сайлау комиссияләренең, участок сайлау комиссияләренең сайлау бюллетеньнәрен алулары турында, шулай ук файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен (бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә) юкка чыгару турында актлар;

в) округ сайлау комиссияләренә, участок сайлау комиссияләренә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү турында, шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларын (таныклыкларның саны күрсәтелә) юкка чыгару турында актлар.

8. Җыелма таблицага һәм актларга округ сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза салалар. Округ сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үзенең аерым фикерен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

9. Округ сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсенең беренче нөсхәсенә округ сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук әлеге Законның бозылуына карата шушы комиссиягә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм әлеге шикаятьлар (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлар теркәлеп куела. Аерым фикерләренең, шикаятьләрнең (гаризаларның) һәм күрсәтелгән сайлау комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

10. Округ сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның һәм актларның беренче нөсхәләре имзаланганнан

соң, кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

11. Округ сайлау комиссиясе беркетмәсенең икенче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның, актларның икенче нөсхәләре белән, шулай ук әлеге Законда каралган бүтән документлар белән бергә, саклаучан бинада, пломба салып мөһерләнгән килеш, комиссиянең вәкаләтләре тәмамланганга кадәр округ сайлау комиссиясе секретарында саклана, шуннан соң Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

12. Округ сайлау комиссиясе беркетмәсенең өченче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның һәм актларның өченче нөсхәләре округ сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында танышу өчен эленеп куела.

Кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, вәкилләргә, комиссиянең хәлиткеч һәм киңәш бирү тавышы хокукларына ия әгъзаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына беркетмәнең күчермәсен алу мөмкинлеге бирелә.

13. Округ сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсенә һәм (яисә) җыелма таблицага имза салынганнан соң һәм аларның беренче нөсхәләрен Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәргәннән соң беркетмәне, җыелма таблицаны төзегән округ сайлау комиссиясе аларда төгәлсезлекләр (участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең күрсәткечләрен кушып берләштергәндә төшеп калган, дөрес язылмаган очраклар яисә хаталар) тапса, округ сайлау комиссиясе үзенең утырышында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тиеш. Округ сайлау комиссиясе кабул ителгән карар турында үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта округ сайлау комиссиясе сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица төзи, аларда «Кабат» дигән тамга салына. Күрсәтелгән беркетмә, җыелма таблица кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәреләләр.

14. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә хаталар, төгәлсезлекләр табылганда яисә участок сайлау комиссияләреннән килгән беркетмәләрнең дөрес төзелешенә шикләнүләр туган очракта, округ сайлау комиссиясе тиешле сайлау участогында сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

15. Әлеге статьяның 14 пунктында күрсәтелгән очракта сайлаучыларның тавышларын кабат санау, тавыш бирү йомгаклары турында тикшерелергә тиешле беркетмәне төзегән һәм раслаган округ сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында, участок сайлау комиссиясе тарафыннан уздырыла. Сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыручы участок сайлау комиссиясе бу хакта сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә хәбәр итә. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча әлеге санауны гамәлгә ашырган сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга салына. Әлеге беркетмә кичекмәстән округ сайлау комиссиясенә җибәрелә.

16. Сайлаулар йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салынганнан соң тиешле округ сайлау комиссиясе бу хакта Татарстан Республикасы халык депутаты булып сайланган кандидатка хәбәр итә. Татарстан Республикасы халык депутаты булып сайланган кандидат, әгәр аның эш урыны яисә шөгыле Татарстан Республикасы халык депутаты статусына туры килмәсә, үзенең шушы вазыйфаларын үз өстеннән төшерүе турында ике атна эчендә язма рәвештә тиешле округ сайлау комиссиясенә әлеге Законның 20 статьясы таләпләре нигезендә хәбәр итәргә итеш.

Округ сайлау комиссиясе буенча сайлауларның нәтиҗәләре турындагы хәбәр Үзәк һәм тиешле округ сайлау комиссияләре тарафыннан Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән вакытларда һәм рәвештә матбугатта басылып чыга.».

30 статья. 35 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**35 статья.** Кабат тавыш бирү

1. Әгәр, сайлау округы буенча халык депутатына икедән артык кандидат чыгып, аларның берсе дә сайланмаса, тиешле округ сайлау комиссиясе иң күп тавыш җыйган ике халык депутатына кандидат буенча сайлау округында кабат тавыш бирүне уздыру турында карар кабул итә. Халык депутатына берничә кандидат җыйган тавышлар бертигез булганда, бюллетеньгә алданрак теркәлгән ике халык депутатына кандидат кертелә. Округ сайлау комиссиясе бу карар турында Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә һәм округ сайлаучыларына җиткерә. Әгәр сайлау бюллетенендә бер кандидат калса, округ сайлау комиссиясе бу хакта өстәмә рәвештә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә һәм округ сайлаучыларына җиткерә.

2. Сайлау округында кабат тавыш бирү, ике атнадан да соңга калмыйча, әлеге Закон таләпләрен үтәгән килеш уздырыла. Кабат тавыш бирү турындагы хәбәр матбугатта басылып чыга.

3. Округта теркәлгән сайлаучыларның кимендә чиреге кабат тавыш бирүдә катнашса, кабат тавыш бирү узган дип санала.

4. Кабат тавыш бирүдә иң күп тавыш җыйган халык депутатына кандидат сайланган дип санала. Җыелган тавышлар бертигез булганда, алданрак теркәлгән халык депутатына кандидат сайланган дип санала.

Халык депутатына бер генә кандидат өчен кабат тавыш биргәндә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышының кимендә 50 процентын җыйса, ул сайланган дип санала.».

31 статья. 37 статьяда «алты ай калгач» дигәч сүзләрне «бер ел калгач» дип алыштырырга.

32 статья. 38 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38 статья. Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдалану

1. Сайлаулар уздырганда дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин.

2. Сайлаулар уздырганда, шул исәптән сайлаучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм сайлауларның нәтиҗәләрен ачыклаганда,

дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасын тулаем яисә аның аерым программ-техник чараларын гына файдалану тәртибе һәм регламенты турындагы карарны, тавыш бирү көненә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабул итә.

3. Дәүләтнең мәгълүмат системасыннан (аның аерым программ-техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясендә һәм округ сайлау комиссияләрендә комиссия әгъзаларыннан төркемнәр төзелә. Сайлау комиссиясенең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелүче яисә аннан алынучы теләсә нинди мәгълүмат белән танышырга хокуклы.

4. Тавыш бирүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша алынган белешмәләр юридик көчкә ия булмаган якынча мәгълүмат кына була.».

II. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2305

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 657. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

I. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994 ел, №12, 158 статья) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 2 статьяның 3 пунктында «затлар» сүзеннән соң өтерне алырга; «шулай ук психиатрия хастаханәләрендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья. 3 статьяда:

2 пунктны 3 пункт дип санарга.

статьяга түбәндәге эчтәлектә 2 пунктны өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары буенча халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар башка вакытка күчерелергә мөмкин, әмма бу вакыт дүрт айдан да артмаска тиеш.».

3 статья. 4 статьяда:

1 өлешендә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы» сүзләре урынына «Дәүләт Советы» сүзләрен язарга, «президиумнар» сүзләрен төшереп калдырырга, «50» цифрын «75»кә алмаштырырга;

2 өлешендә «шәһәр Советы президиумы» сүзләрен «халык депутатларының шәһәр Советы» сүзенә алмаштырырга, «президиум» сүзен төшереп калдырырга, «Советы» сүзе алдыннан «халык депутатларының» сүзләрен язарга;

«15 тән алып 30 депутатка» сүзләре урынына «7дән алып 25 депутатка» сүзләрен язарга.

4 статья. 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары депутатлыгына кандидатларны күрсәтү хокукына сайлаучыларның эш (уку, хезмәт) һәм яшәү урыны буенча җыелышлары, үзен үзе күрсәтү тәртибендә - сайлаучылар, шулай ук законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары ия.

Сайлауларның дәрәҗәләренә туры килә торган дәрәҗәдә законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сәяси-иҗтимагый берләшмәләрнең исемлеге, сайлаулар көне игълан ителгәч җиде көннән дә соңга калмыйча, Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан тапшырыла.

Кандидатны күрсәтү зат сайланырга ризалык бирү турында язмача гариза биргәндә мөмкин, бу гаризада биографик характердагы белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, ае, көне, белеме, төп эш яисә

хезмәт урыны (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда - шөгеленең төре), биләгән эш урыны, кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгәнлеге булганда, имзалар кәгазендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылучы гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы нигезендә хөкем ителгәнлеге булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш, гражданлыгы күрсәтелә, шул исәптән чит дәүләт гражданлыгы (аны алу датасы һәм нигезләрен кертеп) күрсәтелә, Россия Федерациясе Дәүләт Думасына да сайлаулар бер үк вакытта уздырылган очракта, фәкать бер сайлау округыннан гына күрсәтелүе турында, ә сайланган очракта - депутат статусына туры килми торган эшчәнлеген туктатуы яисә бүтән төрле сайланулы урында эшләмәячәге турында йөкләмә тапшырыла. Әлеге гариза, имзалар җыюны башлау турындагы хәбәрнамә белән бергә, тиешле сайлау комиссиясенә җибәрелә.».

5 статья. 6 статьяда:

1 пунктка түбәндәге эчтәлектә икенче абзац өстәргә:

«Халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар уздыру чыгымнары Татарстан Республикасының Республика бюджетында аерым юл белән күрсәтелә. Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар, сайлаулар билгеләнгәннән соң 25 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе карамагына җибәрелә һәм 3 көн эчендә барлык сайлау комиссияләре арасында бүленә.»;

1 пунктка түбәндәге эчтәлектә өченче абзац өстәргә:

«Өстәмә сайлауларны (төшеп калган депутатлар урынына) финанслау район, шәһәр, шәһәрдәге район бюджетлары акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Әлеге сайлауларны уздыру чыгымнары җирле бюджетларда аерым юл белән күрсәтелә.»;

2 пунктта «фирка оешмалары һәм иҗтимагый хәрәкәтләр» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 4 пунктны өстәргә:

«4. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларны тоту турындагы хисапны, сайлаулар нәтиҗәләре басылып чыккач 60 көннән дә соңга калмыйча, - Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, ә район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре, 30 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыралар.

Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе кабат һәм өстәмә сайлаулар уздыруга җирле бюджеттан бүлеп бирелгән акчаларны тоту турындагы хисапны, сайлаулар нәтиҗәләре басылып чыккач 30 көннән дә соңга калмыйча, халык депутатларының җирле Советына тапшыра.».

6 статья. 7 статьяда «үз вәкаләтләре» сүзләрен төшереп калдырырга, аның урынына «әлеге Законда билгеләнгән вәкаләтләр» дип язарга.

7 статья. 8 статьяда:

3 пунктта «сәяси фиркаләрнең, хәрәкәтләрнең һәм бүтән иҗтимагый оешмаларның» дигән сүзләр урынына «иҗтимагый берләшмәләрнең» дигән сүзләрне язарга.

3 пунктта соңгы җөмләне төшереп калдырырга;

4 һәм 5 пунктларны 6 һәм 7 пунктлар дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 4 пунктны өстәргә:

«4. Вәкилләр һәм күзәтүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

а) сайлаучыларның исемлекләре белән танышырга;

б) тавыш бирү көнендә тиешле сайлау участогының тавыш бирү бинасында булырга;

в) сайлаучылар тавыш бирү бинасыннан тыш тавыш биргәндә катнашырга;

г) сайлаучылар исемлекләренә кертелгән гражданнарның санын, сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре санын, юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре санын исәпләп чыгаруны күзәтергә; сайлау участогында тавыш бирү бюллетеньнәренең эчтәлеге күренерлек ераклыкта һәм шартларда сайлаучыларның тавышларын исәпләп чыгаруны күзәтергә; сайлаучыларның тавышларын исәпләп чыгарганда теләсә кайсы тутырылган яисә тутырылмаган сайлау бюллетене белән танышырга; тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне һәм башка төрле документларны сайлау

комиссиясе төзегәнне күзәтеп торырга;

д) тавыш бирүне оештыру мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белән сайлау комиссиясе рәисенә мөрәҗәгать итәргә, ә ул булмаганда - аны алыштыручы затка;

е) тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясе беркетмәсе белән, шулай ук тавыш бирү йомгаклары һәм сайлауларның нәтиҗәләре турында башка төрле сайлау комиссияләре беркетмәләре белән танышырга; күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушымта итеп бирелгән документларның, шулай ук тиешле сайлау комиссияләренә тапшырылган бүтән төрле документларның күчермәләрен, шул исәптән тавыш бирүдә катнашкан затларның исемлеге күчермәсен, тиешле сайлау комиссиясеннән әзерләтергә йә алырга. Күзәтүче таләбе буенча сайлау комиссиясе әлеге күчермәләрне бирергә яисә таныкларга тиеш;

ж) участок сайлау комиссиясенең, башка төрле сайлау комиссиясенең гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка шикаять белдерергә;

з) тиешле сайлау комиссияләрендә сайлаучыларның тавышларын кабат санаганда катнашырга.»;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 5 пунктны өстәргә:

«5. Сайлау комиссиясе утырышларында тавыш бирүдә һәм сайлау нәтиҗәләренә йомгак ясауда катнашучы вәкилләр һәм күзәтүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

а) сайлаучыларга сайлау бюллетеньнәре һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирергә;

б) сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетеньнәрен һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын алуы турында аның өчен имза салырга;

в) сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетеньнәрен тутырырга;

г) тавыш бирү яшеренлеген бозарлык башка гамәлләр кылырга;

д) сайлау комиссияләре әгъзалары сайлау бюллетеньнәрен санаганда турыдан-туры катнашырга;

е) сайлау комиссиясе эшенә комачауларлык гамәлләр кылырга;

ж) сайлаучылар арасында үгетләү эшләре алып барырга;

з) тиешле сайлау комиссиясе карарлар кабул иткәндә катнашырга.».

8 статья. 11 статьяда:

4 пунктның соңгы җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлаучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә, аңа участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала, участок сайлау комиссиясе мөһере сугыла һәм, сайлауларга кадәр 20 көн кала, гомуми танышу өчен тәкъдим ителә.»;

5 пунктта «ике көннән дә соңга калмыйча, ә сайлаулар алдыннан» дигән сүзләрне төшереп калдырырга һәм аларны «24 сәгать эчендә,» дигән сүзләргә алмаштырырга, ә «сайлауларга кадәр биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга, «өч көн эчендә» дигән сүзләрдән соң «тавыш бирү көнне кичекмәстән» сүзләренә алмаштырырга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 6 пунктны өстәргә:

«6. Тавыш бирү тәмамланып, сайлаучыларның тавышларын санау башланганнан соң сайлаучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәртүләр кертү тыела.».

9 статья. 13 статьяның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район, шәһәр, шәһәрдәге район Советларына халык депутатларын сайлауларны оештыру һәм уздыру буенча сайлау комиссияләре төзелә.»;

статьяга түбәндәге эчтәлектә абзац өстәргә:

«Җирле Советларга халык депутатларын сайлауларны әзерләү, әлеге Законның үтәлешен контрольдә тоту, район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре белән берлектә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

10 статья. 14 статьяда:

1 пунктта «18» цифрын «12» гә алмаштырырга, икенче җөмләгә «иҗтимагый берләшмәләр, сайлаучыларның эш (хезмәт, уку) һәм яшәү урыннары буенча җыелышлары тәкъдимнәрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә, «халык депутатларының тиешле җирле Советлары» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

2 пунктка «иҗтимагый берләшмәләр, сайлаучыларның эш (хезмәт,уку) һәм яшәү урыннары буенча җыелышлары тәкъдиме нигезендә» сүзләрен өстәргә.

11 статья. 15 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлау комиссияләре вәкаләтләре»;

1 һәм 2 өлешләрне 2 һәм 3 өлешләр дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 1 өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе:

район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләрен раслый;

район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре белән берлектә җирле Советларга халык депутатлары сайлауларны әзерли һәм уздыра, әлеге Законның үтәлешен тикшереп тора;

кабат сайлауларны билгели;

халык депутатларының җирле Советларына халык депутатларын сайлаулар уздыруга тотылган чыгымнар хакындагы хисапны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыра;

республика һәм федераль сайлаулар турындагы законнар нигезендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.»;

2 өлешнең «г» пунктына «сайлаучыларга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыралар» дигән сүзләрне өстәргә;

«к» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) сайлаулар уздыру өчен үзләренә бүлеп бирелгән акчалар һәм матди чаралар белән эш итәләр, Үзәк сайлау комиссиясенә һәм халык депутатларының тиешле Советларына финанс хисабын раслау өчен тапшыралар;».

12 статья. 16 статьяның 1 өлешендәге «г» пунктына «сайлаучыларга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыра» сүзләрен өстәргә.

13 статья. Түбәндәге эчтәлектә 16[1] статьясын кертергә:

«16[1] статья. Сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының статусы

Сайлау комиссиясе составына депутатлар, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлап куелучы урындагы затлары, судьялар, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатларны күрсәткән сайлаучылар җыелышларының, сайлау берләшмәләренең һәм сайлау блокларының вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары, сайлау комиссияләренең

киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, кандидатларның, теркәлгән кандидатларның ире йә хатыны, якын туганнары яисә кандидатларның, теркәлгән кандидатларның турыдан-туры буйсынуындагы затлар керә алмыйлар.

Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлау комиссиясенең барлык утырышларында катнашырга тиеш.

Сайлау комиссиясе әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

тиешле сайлау комиссиясе утырышлары хакында алдан хәбәр алырга;

сайлау комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле сайлау комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирүне уздыруны таләп итәргә;

сайлау комиссиясе утырышында башка катнашучыларга көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр нигезендә сораулар бирергә һәм аларга төпле җаваплар алырга;

тиешле һәм түбәнгерәк сайлау комиссияләренең машинадан укыла торган саклагычлардагы документларын һәм материалларын да кертеп, теләсә кайсы документлар һәм материаллар (шул исәптән сайлаучылар исемлекләре, сайлау бюллетеньнәре) белән танышырга, һәм аларның (сайлаучылар исемлекләреннән, сайлау бюллетеньнәреннән тыш) күчермәләрен алырга һәм бу күчермәләрне таныклауны таләп итәргә.

Сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләр чоры тәмамланганчы сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан үзен билгеләгән орган карары буенча түбәндәге очракларда азат ителә:

сайлау комиссиясе әгъзасының вәкаләтләрен үз өстеннән төшерүе хакындагы язмача гаризасы булганда;

Татарстан Республикасыннан, районнан һәм шәһәрдән даими яшәү урынына күчеп киткәндә;

сайлау комиссиясе әгъзасына карата судның хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалану сәләте чикләнгән, кайдалыгы билгесез яисә вафат булган дип танылганда;

Татарстан Республикасы гражданлыгын югалтканда;

сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларын даими рәвештә үтәмәгәндә - сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча;

әлеге Законда каралган бүтән төрле нигезләр булганда.

Җирле, республика һәм федераль сайлаулар бер үк вакытта уздырылган очракта, район, шәһәр, шәһәрдәге район һәм участок сайлау комиссияләренең төп эшеннән азат ителгән рәисенә һәм секретарена, сайлаулар көненә 60 көн кала, сайлаулар уздыру өчен бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы Республика бюджеты акчалары исәбеннән ай саен хезмәт өчен түләү башкарыла, аның күләме Татарстан Республикасындагы биш минималь хезмәт хакыннан артык булмаска тиеш.Сайлауларны әзерләү һәм уздыру чорында сайлау комиссиясенең төп эшләреннән азат ителгән башка әгъзаларына хезмәт өчен түләү сайлаулар уздыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла, аның күләме төп эш урыннарындагы уртача хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш, пенсионерлар һәм вакытлыча эшләмичә торучылар өчен - Татарстан Республикасы буенча уртача хезмәт хакы күләмендә.

Үз вәкаләтләре чорында сайлау комиссиясе әгъзасы администрация (эш бирүче) инициативасы белән эштән азат ителә алмый яки комиссия әгъзасының ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый.

Сайлаулар уздыру чорында сайлау комиссиясе әгъзасы Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка суд тәртибендә билгеләнә торган җинаять җаваплылыгына һәм административ җәза гамәлләренә тартыла алмый.».

14 статья. Түбәндәге редакциядә $16^2$ статьясы өстәргә:

«$16^2$ статья. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары статусы

Сайлау комиссиясе тарафыннан кандидат теркәлгәннән соң, әлеге кандидат үзен теркәгән түбәнгерәк сайлау комиссияләренә киңәш бирү тавышы хокукына ия берәр әгъза билгеләп куярга хокуклы.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы бер үк вакытта бүтән төрле сайлау комиссиясе әгъзасы була алмый.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы сайлауларны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының бөтен

хокукларына да тулаем ия була.

Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

бүтән сайлау округында тавыш бирү таныклыклары, сайлау бюллетеньнәре бирергә;

сайлау бюллетеньнәрен сортировкалауда һәм санауда катнашырга;

тавыш бирү йомгаклары һәм сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә төзегәндә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларын кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларына имза салырга.».

15 статья. 17 статьяда:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау комиссиясенең карарлары ачык яки яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Сайлау комиссиясе рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлау турында, халык депутатына кандидатларны теркәү турында, сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанслау мәсьәләләре буенча, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү турында, сайлауларны узмаган яки гамәлгә яраксыз дип тану турында, кабат тавыш бирү яки кабат сайлаулар уздыру турында сайлау комиссиясе карарлары тиешле сайлау комиссиясе утырышларында сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

Сайлау комиссиясенең башка төрле мәсьәләләр буенча карарлары сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия шунда катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Сайлау комиссияләре карарлар кабул иткәндә хуплап һәм каршы бирелгән тавышлар саны бертигез булса, сайлау комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Сайлау комиссиясе карарына сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала.

Сайлау комиссиясе кабул иткән карар белән килешмәгән сайлау комиссиясе әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язмача белдерергә хокуклы, бу фикер, өч көннән дә соңга калмыйча, ә сайлауларга өч көн кала һәм сайлаулар көнендә кичекмәстән сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан югарырак

сайлау комиссиясенә җиткерелә.

Сайлау комиссиясенең законны бозган килеш кабул ителгән карары югарырак сайлау комиссиясе яки суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш.»;

7 пунктны төшереп калдырырга;

8,9,10 пунктларны 7,8,9 пунктлар дип санарга.

16 статья. 19 статьяда:

3 пунктка түбәндәге эчтәлектә беренче һәм икенче җөмлә кертергә:

«Халык депутатларының җирле Советларына депутатлыкка кандидатларны үзен үзе күрсәтү юлы белән турыдан-туры сайлаучылар үзләре, шулай ук сайлаучыларның эш (хезмәт, уку) һәм яшәү урыны буенча җыелышлары, законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары күрсәтә ала. Кандидатны күрсәтү хакында кандидат теркәләчәк тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенә хәбәр ителә.»;

3 пункттагы 1 абзацта «Фиркаләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең район, шәһәр бүлекләре» дигән сүзләрне «сайлаулар дәрәҗәсенә туры килерлек сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

3 пункттагы 1 абзацка түбәндәге җөмлә өстәргә:

«Үзен үзе кандидат итеп күрсәтү кандидатның тиешле сайлау комиссиясенә тулы биографик мәгълүматлар теркәлгән һәм үзен яклап имзалар җыячагы хакында хәбәр иткән язмача гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла».

3 пункттагы 2,3,4,5 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары һәр сайлау округында халык депутатына берәр кандидат күрсәтергә хокуклы.

Сайлаучылар җыелышларында һәм сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары карарлар кабул иткәндә чикләнмәгән сандагы кандидатуралар буенча фикер алышулар өчен шартлар тудырыла. Сайлаучылар җыелышында һәр катнашучы, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының һәр әгъзасы халык депутатына кандидатлар хакында тәкъдимнәр кертергә, алар турында фикер алышуларда катнашырга, тәкъдим ителгән кандидатураларны хупларга йә аларны кире кагу турында тәкъдимнәр кертергә, халык депутатына кандидат сыйфатында

фикер алышулар өчен үз кандидатурасын тәкъдим итәргә хокуклы.

Халык депутатына кандидат күрсәтү хакындагы карар ачык яисә яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү тәртибе һәм башка процедура мәсьәләләре сайлаучылар җыелышында билгеләнәләр.

Сайлаучылар җыелышында катнашучыларның яртысыннан артыграгы халык депутатына кандидат өчен тавыш бирсә, ул күрсәтелгән дип санала. Сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары халык депутатына кандидат күрсәтү хакындагы карарны үзләренең гамәлгә кую документларында билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр. Халык депутатына кандидат күрсәтү хакында беркетмә төзелә. Кабул ителгән карар турында, ике көннән дә соңга калмыйча, халык депутатына кандидатка хәбәр ителә.»;

5 пунктка түбәндәге җөмләләрне өстәргә:

«Кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, имзалар кәгазендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит дәүләт законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Кандидатның чит ил гражданлыгы булса, имзалар кәгазендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.».

6 пунктка икенче җөмләдән соң түбәндәге 5 җөмләне кертергә:

«Кандидатларны теркәү өчен тиешле сайлау комиссиясенә кандидатның шулай ук милек хокукындагы мөлкәте һәм керемнәре турындагы белешмәләр тапшырылырга тиеш. Керемнәренең күләме һәм чыганаклары хакындагы белешмәләр кандидат булган гражданның сайлаулар билгеләнгән елга кадәр узган ел өчен керемнәре турындагы декларациянең күчермәсе рәвешендә (салым органнары куйган тамга белән) тапшырыла. Кандидат булган граждан салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә керемнәре хакында декларация бирергә тиеш булмаган очракта, керемнәр

алган урын буенча оешмадан сайлаулар билгеләнгән елга кадәр узган ел өчен аның тулаем керемнәре хакындагы белешмә тапшырыла. Кандидатның милек хокукындагы мөлкәте турындагы белешмәләр әлеге Закон кушымтасында билгеләнгән рәвештә тапшырыла.

Сайлау комиссиясе әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турындагы тәкъдим белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

9 пунктны 10 пункт дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 9 пунктны өстәргә:

«9. Әгәр калган имзалар саны әлеге Закон таләпләре нигезендә теркәлү өчен билгеләнгән саннан кимрәк булса, имза салу кәгазьләрендә дөрес булмаган имзалар саны ачыкланганда, халык депутатына кандидатның теркәлүе суд тәртибендә юкка чыгарыла.».

17 статья. 20 статьяда:

1 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

5 пункттагы 1 абзацта «һөнәр берлекләренең һәм башка иҗтимагый берләшмәләрнең район, шәһәр бүлекләре» дигән сүзләрне «сайлау берләшмәләре һәм сайлау блоклары» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

5 пункттагы 2 абзацта «фирканең, һөнәр берлегенең һәм башка иҗтимагый берләшмәнең район, шәһәр бүлегенең конференцияләре, пленумы карарлары» дигән сүзләрне «сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының вәкаләтле органы карары» дигән сүзләргә алмаштырырга.

18 статья. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. Халык депутатларының җирле Советлары халык депутаты статусының вазыйфаи хәленә туры килмәве

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре һәм, Премьер-министрдан кала, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының башка әгъзалары, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территория органнары җитәкчеләре, җирле хакимиятләр башлыклары урынбасарлары һәм хакимиятләрнең структур бүлекчәләре җитәкчеләре, шулай ук судьялар халык депутатларының тиешле җирле Советлары депутатлары була алмыйлар.».

19 статья. 22 статьяның 1 пунктында «һөнәр берлекләренең, фиркаләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең район, шәһәр бүлекләре» дигән сүзләрне «сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары» дигән сүзләргә алмаштырырга.

20 статья. 23 статьяның 2,3,4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Сайлау комиссияләре әгъзаларына сайлау алды үгетләве уткәрү, теләсә нинди сайлау алды үгетләве материалларын тарату, шулай ук сайлау комиссияләре биналарында һәм тавыш бирү биналарында да тыела.

3. Сайлаучыларга бушлай яисә ташламалы шартларда товарлар сату, хезмәт күрсәтү (мәгълүмат хезмәтеннән тыш), кыйммәтле кәгазьләр сату, шулай ук акча өләшү юлы белән сайлау алды үгетләве алып бару тыела.

4. Үгетләү кампаниясе кандидатны теркәгән көннән уздырыла башлый һәм сайлаулар көне алдыннан 0 сәгатьтә туктатыла. Сайлаулар алдындагы көн дәвамында һәм тавыш бирү көнендә теләсә нинди сайлау алды үгетләве тыела.».

21 статья. 25 статьядагы «тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе ризалыгыннан башка» дигән сүзләрне «район яки шәһәр прокуроры ризалыгыннан башка» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

22 статья. 26 статьяда:

1 пункттагы дүртенче җөмләдә «ике көн кала» дигән сүзләрне «дүрт көн кала» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

1 пункттагы соңгы җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау бюллетененең алгы ягындагы өстәге уң як почмагына участок комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар участок комиссиясенең мөһере белән таныклаыалар.»;

3 пунктка «шулай ук аның кем тарафыннан күрсәтелгән булуы» сүзләрен өстәргә;

3 пунктка түбәндәге эчтәлектә абзацлар өстәргә:

«Уң якта һәр кандидат турындагы белешмәләр каршысына буш квадрат урнаштырыла. Кандидатлар исемлеге ахырында «Барлык кандидатларга каршы» дигән юл урнаштырыла һәм ул әлеге юлның уң ягындагы буш квадрат каршысында була. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, сайлау

бюллетенендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, сайлау бюллетенендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.».

23 статья. 27 статьяда:

1 өлешнең беренче җөмләсендә «7дән алып 21 сәгатькә кадәр» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары буенча тавыш бирү өчен башка вакыт билгеләнергә мөмкин» дигән сүзләрне язарга;

1 пункттагы икенче җөмләдә «ун» сүзен «егерме» сүзенә алмаштырырга;

3 өлешне төшереп калдырырга.

24 статья. 28 статьяда:

2-9 өлешләрне 3-10 өлешләр дип санарга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә 2 өлеш өстәргә:

«Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү бинасында йә аның каршында ук стенд җиһазлый, анда шушы округ буенча теркәлгән барлык кандидатлар хакында мәгълүмати материаллар урнаштырыла. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгәнлеге булганда, мәгълүмати материалларда Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) номеры (номерлары) һәм исеме (исемнәре), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, мәгълүмати материалларда тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш. Тутырылган сайлау бюллетеньнәре үрнәкләре стендка

урнаштырыла, аларда әлеге округта теркәлгән кандидатларның фамилияләре күрсәтелмәскә тиеш. Мәгълүмати материалларда үгетләү өндәмәләре булмаска тиеш.»;

4 өлештәге икенче, өченче җөмләләрне төшереп калдырырга;

5 өлештә «башка шәхес таныклыгы» сүзләрен «шәхес таныклыгын алыштыручы» сүзләренә алмаштырырга;

6 өлештә «ике» сүзен «өчтән дә артмаган» сүзләренә алмаштырырга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә өлеш өстәргә:

«Участок сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүчеләр һәм башка төрле затлар тавыш бирү яшеренлеген бозсалар яисә сайлаучының тавыш бирү ихтыярына йогынты ясарга маташсалар, участок сайлау комиссиясе әгъзасы эштә катнашудан кичекмәстән мәхрүм ителә, ә күзәтүчеләр һәм бүтән төрле затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарыла. Бу турыдагы карар участок сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.».

25 статья. Законга түбәндәге эчтәлектә 28[1] статья өстәргә:

«28[1] статья. Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлаулар буенча тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы

1. Сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 45-25 көн кала) йә шушы сайлау участогының участок сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 24-1 көн кала) бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алырга һәм, тавыш бирү көнендә кайсы сайлау участогында булса, шунда, үзе актив сайлау хокукына ия булган сайлау округы чикләрендә тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы катгый хисап документы була, аның яклану дәрәҗәсе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләү һәм бирү рәвеше, тәртибе, аларны бирү саны һәм реестр рәвеше, шулай ук аларны әзерләүгә карата куелучы таләпләр,

тавыш бирергә 60 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланалар. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары югарырак сайлау комиссиясеннән түбәнгерәк сайлау комиссиясенә сайлау бюллетеньнәрен тапшыру тәртибендә тапшырылалар. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыручы, алучы һәм саклаучы сайлау комиссияләре рәисләре бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшырган өчен һәм аларның сакланышы өчен җаваплы була.

3. Тиешле сайлау комиссиясе сайлаучының бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын таләп итүнең сәбәбен күрсәтеп язган гаризасы нигезендә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын сайлаучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук сайлаучы дәваланучы стационар дәвалау-профилактика учреждениесе администрациясе тарафыннан да, шик белдерелүче яисә гаепләнүче затны сак астында тотучы учреждение администрациясе тарафыннан да таныкланырга мөмкин.

Администрация башлыгы тарафыннан комиссиягә сайлаучылар турында бирелгән белешмәләр нигезендә район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы тапшыра. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрын төзи, анда сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Тавыш бирергә 25 көн кала район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе, сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне участок сайлау комиссиясенә җибәрә, аларда тиешле сайлау участоклары территорияләрендә теркәлгән һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары алган сайлаучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Шундый өземтә нигезендә участок сайлау комиссиясе сайлаучылар исемлегенә тиешле тамгаларны кертә.

4. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы

алуы турында сайлаучы яисә аның вәкиле бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына (район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясендә) йә сайлаучылар исемлегенә (участок сайлау комиссиясендә) имза салалар, анда паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

Бу чакта шушы сайлаучы әлеге сайлауларда тиешле участок сайлаучылары исемлегеннән төшереп калдырыла һәм участок сайлау комиссиясенең беркетмәсен төзегәндә теркәлгән сайлаучыларның санын санаганда исәпкә алынмый.

5. Әгәр бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгында район, шәһәр, шәһәрдәге район яисә участок сайлау комиссиясенең мөһере һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән район, шәһәр, шәһәрдәге район яисә участок сайлау комиссиясе әгъзасының имзасы булса, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы гамәлгә яраклы дип санала.

6. Тавыш бирү көнендә сайлаучы, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәтеп, үзе актив сайлау хокукына ия булган сайлау округы чикләрендәге теләсә кайсы башка сайлау участогындагы сайлаучылар исемлегенә кертелергә тиеш, шуннан соң бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы аңардан кире алына. Бу чакта сайлаучы сайлау бюллетене (сайлау бюллетеньнәре) алганнан соң сайлаучылар исемлегендә өстәмә рәвештә үзе яшәгән урынның адресын күрсәтә.

7. Тавыш бирү көнендә сайлаучы элек сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогында ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткән очракта, сайлаучы өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә, ә аның бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы аңардан кире алына һәм юкка чыгарыла.

8. Тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы, бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыклары юкка чыгарыла, бу турыда тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район яисә участок сайлау комиссиясе акт төзи.».

26 статья. 29 статьяда:

2 өлештә «яисә җәмәгать күзәтүчесеннән» дигән сүзләрне «теркәлгән кандидаттан, ышанычлы заттан, күзәтүчедән, вәкилдән» дигән сүзләргә алмаштырырга;

3 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау бюллетеньнәрендә сайлаучы үзе тавыш бирә торган кандидат фамилиясенең каршындагы буш квадратка яисә «Барлык кандидатларга каршы» дигән юлдагы квадратка теләсә нинди тамга сала.»;

3 өлештә «тутырылган сайлау бюллетеньнәре» дигән сүзләрне «тутырылган сайлау бюллетене» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

4,5 өлешләрне төшереп калдырырга.

27 статья. 30 статьяны 31 статья дип санарга.

28 статья. Законга түбәндәге статьяны кертергә:

«30 статья. Тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясе беркетмәсе

1. Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) нөсхәнең номеры;

б) сайлауларның исеме, тавыш бирү датасы, сайлау округының исеме һәм номеры;

в) «Беркетмә» сүзе;

г) сайлау участогының номеры күрсәтелгән килеш, сайлау комиссиясенең исеме;

д) беркетмә юллары:

1 юл. Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре саны;

3 юл. Юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре саны;

4 юл. Тавыш бирү көнендә сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

5 юл. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

6 юл. Күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

7 юл. Стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

8 юл. Гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре саны;

9 юл. Гамәлгә яраксыз, шул исәптән кайбер юллары буенча гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәренең гомуми

саны;

10 юл. Тиешле сайлау округы буенча тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләреннән алынган сайлау бюллетеньнәренең саны сайлаучыларның сайлау бюллетеньнәрен алулары турында тамга куелган гаризалары саныннан артып киткәндә, гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау бюллетеньнәре саны;

11 юл. Бер позиция буенча да тамгалары булмаган яисә бердән артыграк позициядә тамгалары булган гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәренең саны;

12 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында тавыш бирү көненә кадәр сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юл. Сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

15 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмыйча юкка чыгарылган таныклыклары саны;

6 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең әлеге Законның 28[1] статьясындагы 7 пункты нигезендә юкка чыгарылган таныклыклары саны;

е) беркетмәгә кушымта итеп бирелүче шикаятьләр (гаризалар), актлар һәм башка документлар исемлеге;

ж) сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретаренең һәм башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары, аларның имзалары;

з) беркетмәгә имза салынган дата һәм вакыт (сәгатьләре һәм минутлары) (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен);

и) сайлау комиссиясе мөһере (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен).

2. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 17 юлына һәм аннан соңгы юлларына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр языла:

теркәлгән кандидатларның алфавит тәртибендә фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алар бер-берсенә тәнгәл килгәндә - сайлау бюллетененә кертелгән теркәлгән кандидатлар турында бүтән күрсәткечләр һәм теркәлгән һәр кандидат өчен сайлаучылар тарафыннан

бирелгән тавышлар саны;

сайлаучылар тарафыннан кандидатларның барысына да каршы бирелгән тавышлар саны.

3. Әлеге статьяның 1-2 пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә цифрлап һәм язмача кертелә.».

29 статья. 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**31 статья.** Участок сайлау комиссиясендә тавышларны санау тәртибе

1. Тавыш бирү вакыты беткәч, участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирүнең тәмамлануы хакында игълан итә.

2. Тавышларны санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен саныйлар, юкка чыгаралар, аннары аларны игълан итәләр һәм аларның санын тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 3 юлына язып куялар.

Юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре санына тавыш биргәндә сайлаучылар тарафыннан бозылган сайлау бюллетеньнәре дә керә.

Шуннан соң участок сайлау комиссиясе әгъзалары бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларының санын игълан итәләр һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 15 юлына язып куялар.

Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең әлеге Законның $28^1$ статьясындагы 7 пункты нигезендә юкка чыгарылган таныклыклары санала, аларның саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 16 юлына язып куела.

3. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы бит буенча түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

а) район, шәһәр, шәһәрдәге район һәм участок комиссияләрендә тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирелгән сайлаучыларны исәпкә алмыйча, исемлеккә кертелгән сайлаучылар санын;

б) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә бирелгән сайлау бюллетеньнәре санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

в) сайлаучыларга тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

г) сайлаучыларга участок сайлау комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары санын;

д) сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар санын.

4. Шушы күрсәткечләр кертелгәннән соң сайлаучылар исемлегенең һәр битенә участок комиссиясенең әлеге күрсәткечләрне язган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, аннары күрсәткечләр сайлаучылар исемлеге буенча кушып берләштерелә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертелә, участок сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының яки секретаренең имзалары һәм мөһер белән таныклана. Һәр бит һәм исемлек буенча йомгаклар тулысынча игълан ителә.

5. Участок сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре түбәндәгеләрне аныклыйлар һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 1 һәм 2 юлларына кертәләр:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын;

б) участок комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре санын.

6. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

12 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юлга - бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча сайлау участогында тавыш биргән сайлаучылар саны.

7. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

4 юлга - тавыш бирү көнендә сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юлга - тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән

сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

8. Бу гамәлләрдән соң участок сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре сайлаучыларның исемлеген, тавышларны санауда катнашучы затлар файдаланмаслык итеп, саклауны тәэмин итәргә тиешләр. Сайлаучылар исемлеге белән алга таба эш итү бары тик тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары тикшерелгәннән соң гына әлеге статьяның 15 пункты нигезендә башкарылырга мөмкин.

9. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирү әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәр буенча сайлаучыларның тавышларын санарга турыдан-туры керешәләр.

Санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясе рәисе сайлау әрҗәләрендә мөһерләрнең яисә пломбаларның бөтенлеген тикшерә һәм аларны ача. Сайлау әрҗәләрен ачу түбәндәге чиратта гамәлгә ашырыла: башта - күчерелмә сайлау әрҗәләре, аннары стационар сайлау әрҗәләре ачыла.

10. Башта күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре санала. Аларның саны игълан ителә һәм беркетмәнең 6 юлына язып куела һәм ул сайлаучыларның тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалары саныннан артмаска тиеш.

Күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге бюллетеньнәр санының бирелгән гаризалар саныннан артып китүе ачыкланган очракта, күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге барлык сайлау бюллетеньнәре участок сайлау комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип танылалар.

Бу факт, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелеп, аерым актта чагылдырыла, ул акт тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.

Бу очракта гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр саны беркетмәнең 9, 10 юлларына кертелә.

11. Аннары стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге бюллетеньнәр санала һәм аларның саны беркетмәнең 7 юлына язып куела.

12. Сайлаучыларның тавышларын санаганда, иң элек билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр, ягъни рәсми рәвештә эшләнмәгән яисә сайлау комиссиясе тарафыннан таныкланмаган бюллетеньнәр һәм гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәре аерып алына. Бу бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

13. Сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерүләрен төгәл ачыклап булмый торган сайлау бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дип санала, мондыйларга түбәндәгеләр керә:

бердән артык квадратка билге куелган бюллетеньнәр;

квадратларның берсенә дә билге куелмаган бюллетеньнәр.

Шикләнүләр туган очракта, участок сайлау комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә. Бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тану турында карар кабул иткәндә, сайлау комиссияләре аның арткы ягында бюллетеньнең гамәлгә яраксызлыгының сәбәпләрен күрсәтәләр. Бу язма участок комиссиясе рәисенең һәм секретаренең имзалары белән таныклана. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр башка сайлау бюллетеньнәреннән аерым җыеп тутырыла.

Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны 9,11 юлларга кертелә.

14. Участок комиссиясе әгъзалары беркетмәнең 8 юлына гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре санын язып куялар.

15. Сайлау бюллетеньнәрен санаганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары (4 нче кушымта) тикшерелә. Алар тәңгәл килмәгән очракта, участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юлларын кабат санау турында карар кабул итә. Кабат санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәрешләр кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла.

16. Санаганнан соң теркәлгән кандидатлар буенча сайлау бюллетеньнәре аерым капларга, кандидатларның барысына да каршы тавыш бирелгән бюллетеньнәр - аерым, шулай ук гамәлгә яраксыз һәм юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре аерым капларга тутырыла, һәр капта андагы сайлау бюллетеньнәренең саны, теркәлгән кандидатларның фамилияләре күрсәтелә. Шулай тупланган сайлау бюллетеньнәре капчыкларга яисә тартмаларга салына, аларда сайлау участогының,

округының үз номерлары (исеме), сайлау бюллетеньнәренең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга пломба салып, мөһер сугыла. Һәм алар бары тик югарырак сайлау комиссиясе яисә суд карары белән генә ачылырга мөмкин.

17. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә өч нөсхәдә тутырыла һәм аларга участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда имза салынган дата һәм вакыт (сәгате, минуты) куела.

18. Беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәгән участок сайлау комиссиясе әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерләрен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

19. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

20. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, тиешле законның бозылуына карата участок сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар), шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлеп куела. Әлеге документларның таныкланган күчерелмәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

21. Беркетмәнең беренче нөсхәсе кичекмәстән район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенә җибәрелә.

22. Беркетмәнең икенче нөсхәсе, пломба салып мөһерләнгән сайлау документлары белән бергә, сайлау бюллетеньнәрен һәм мөһерне дә кертеп, саклanучан бинада, пломба салып мөһерләнгән килеш, участок комиссиясе эше тәмамланганчы участок комиссиясе секретаренда саклана һәм сайлаулар йомгакларын рәсми игълан иткәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенә тапшырыла.

23. Беркетмәнең өченче нөсхәсе участок сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында гомуми танышу өчен эленеп куела.».

30 статья. 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32 статья. Сайлау округында сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү

1. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йом-

гаклары турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләр нигезендә тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе аларның дөрес төзелүен алдан тикшерганнан соң, тавыш бирганнан соң ике көннән дә сонга калмыйча, алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендәге күрсәткечләрне кушып берләштерүне шул район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үзләре башкаралар.

2. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлауларны түбәндәге очракларда узмаган дип таный:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның сайлауларда 35 проценттан кимрәге катнашканда (сайлауларда катнашкан сайлаучыларның саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 4,5 юлларындагы саннар суммасы белән билгеләнә);

б) бүтән кандидатка (бүтән кандидатларга) караганда иң күп тавыш җыйган кандидат өчен бирелгән сайлаучылар тавышларының саны барлык кандидатларга да каршы бирелгән сайлаучылар тавышлары санынннан кимрәк булганда;

в) сайлау округы буенча халык депутатына бер генә кандидат теркәлеп, ул да кандидатлыктан төшеп калганда.

3. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлаулар нәтиҗәләрен түбәндәге очракларда гамәлгә яраксыз дип таный:

а) тавыш бирүне уздырганда яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә әлеге Законны бозу сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәгәндә;

б) сайлау округы буенча тавыш бирү йомгаклары гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау участокларының саны шушы сайлау округы территориясендә оештырылган сайлау участокларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил иткәндә;

в) суд карары буенча.

4. Әлеге Законны, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмый калган теркәлгән кандидатларның сайлануына

ярдәм итәрлек итеп, йә тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмый калган теркәлгән кандидатлар өчен сайлаучыларны тавыш бирергә мәҗбүр итү максаты белән яисә мәҗбүр итеп бозу сайлауларны гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.

5. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе тиешле участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре нигезендә сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, аңа түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

а) сайлау округында участок сайлау комиссияләренең саны;

б) участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре саны, шуларга нигезләнеп әлеге беркетмә төзелә;

в) участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендә булган барлык юллар буенча сайлау округының суммар күрсәткечләре;

г) депутат булып сайланган теркәлгән кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме.

6. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының 50 процентыннан күбрәген җыйган теркәлгән кандидат сайлау округы буенча сайланган дип таныла. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның тавышлары саны тавыш бирү әрҗәләреннән алынган мәгълүм рәвештәге сайлау бюллетеньнәре саны буенча билгеләнә.

7. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсе өч нөсхәдә төзелә, аңа район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда аны төзү датасы һәм вакыты (сәгате һәм минуты) күрсәтелә һәм алар мөһер белән таныкланалар. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә түбәндәгеләр теркәлеп куела:

а) сайлау округы буенча сайлаулар нәтиҗәләре турында җыелма таблица, аңа тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләреннән алынган барлык беркетмәләрнең күрсәткечләре тулаем кертелә;

б) район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләренең, участок сайлау комиссияләренең сайлау

бюллетеньнәрен алулары турында, шулай ук файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен (бу бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә) юкка чыгару турында актлар;

в) район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләренә, участок сайлау комиссияләренә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү турында, шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларын (бу таныклыкларның саны күрсәтелә) юкка чыгару турында актлар.

8. Җыелма таблицага һәм актларга район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза салалар. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үзенең аерым фикерен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

9. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсенең беренче нөсхәсенә район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук әлеге Законның бозылуына карата шушы комиссиягә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм әлеге шикаятьлар (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлар теркәлеп куела. Аерым фикерләрнең, шикаятьләрнең (гаризаларның) һәм күрсәтелгән сайлау комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

10. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның һәм актларның беренче нөсхәләре имзаланганнан соң кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

11. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе беркетмәсенең икенче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның, актларның икенче нөсхәләре белән, шулай ук әлеге Законда каралган бүтән документлар белән бергә, саклanучан бинада, пломба салып мөһерләнгән килеш, комиссиянең вәкаләтләре тәмамланганга кадәр район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе секретаренда саклана, шуннан соң Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

12. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе беркетмәсенең өченче нөсхәсе, әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның һәм актларның өченче нөсхәләре район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында танышу өчен эленеп куела.

Кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, вәкилләргә, комиссиянең хәлиткеч һәм киңәш бирү тавышы хокукларына ия әгъзаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына беркетмәнең күчермәсен алу мөмкинлеге бирелә.

13. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсенә һәм (яисә) җыелма таблицага имза салынганнан соң һәм аларның беренче нөсхәләрен Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәргәннән соң беркетмәне, җыелма таблицаны төзегән район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе аларда төгәлсезлекләр (участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең күрсәткечләрен кушып берләштергәндә төшеп калган, дөрес язылмаган очраклар яисә хаталар) тапса, район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе үзенең утырышында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тиеш. Район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе кабул ителгән карар турында комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица төзи, аларда «Кабат» дигән тамга салына. Күрсәтелгән беркетмә, җыелма таблица кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

14. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә хаталар, төгәлсезлекләр табылганда яисә участок сайлау комиссияләреннән кергән беркетмәләрнең дөрес төзелешенә шикләнүләр туган очракта, район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе тиешле сайлау участогында сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

15. Әлеге статьяның 14 пунктында күрсәтелгән очракта сайлаучыларның тавышларын кабат санау, тавыш бирү

йомгаклары турында тикшерелергә тиешле беркетмәне төзегән һәм раслаган район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенең хәлиткеч хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында, участок сайлау комиссиясе тарафыннан уздырыла. Сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыручы участок сайлау комиссиясе бу хакта сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә хәбәр итә. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча әлеге санауны гамәлгә ашырган сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга салына. Әлеге беркетмә кичекмәстән район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенә җибәрелә.

16. Сайлаулар йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салынганнан соң тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясе бу хакта Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты булып сайланган кандидатка хәбәр итә. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты булып сайланган кандидат, әгәр аның эш урыны яисә шөгыле Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусына туры килмәсә, үзенең шушы вазыйфаларын үз өстеннән төшерүе турында ике атна эчендә язма рәвештә тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссиясенә әлеге Законның 21 статьясы таләпләре нигезендә хәбәр итәргә тиеш.

Округ сайлау комиссиясе буенча сайлауларның нәтиҗәләре турындагы хәбәр Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән вакытларда һәм рәвештә Үзәк һәм тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре тарафыннан матбугатта бастырып чыгарыла.».

31 статья. 33 статьяны төшереп калдырырга. 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42, 43 статьяларны 33, 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42 статьялар дип санарга.

32 статья. 34 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатларны теркәү турында бәхәсләр законда билгеләнгән вакытларда Үзәк сайлау комиссиясе яки район

(шәһәр) суды тарафыннан карала.».

33 статья. 35 статьяда:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хәбәрдә сайлаучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның гомуми саны һәм тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саны күрсәтелә;

сайлаучыларның һәр кандидатны хуплап биргән тавышлары саны һәм «Барлык кандидатларга каршы» бирелгән тавышлар саны;

тиешле округта кабат тавыш бирү яисә кабат сайлаулар уздыру турында мәгълүмат.»;

3 өлештә «ул сайланган сайлау округының номеры» дигән сүзләрне «алар сайланган сайлау округларының номерлары» дигән сүзләргә алмаштырырга.

3 өлешкә түбәндәге җөмләне өстәргә:

«Сайланган депутатлар исемлеге Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.».

34 статья. 37 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлаучылар исемлегенең, сайлау бюллетеньнәренең, кандидатларны теркәү беркетмәләренең, депутатлыкка кандидат, ышанычлы зат таныклыкларының, сайлау участогында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрнең, округта сайлау нәтиҗәләре турындагы беркетмәләрнең рәвешләре, сайлау әрҗәләренең үрнәкләре Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Депутатның күкрәк тамгасының үрнәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.».

35 статья. 38 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау документларын саклау тәртибе һәм вакытлары Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.».

36 статья. 39 статьяда:

2 өлешкә түбәндәге җөмләне өстәргә:

«Округта теркәлгән сайлаучыларның кимендә чиреге кабат тавыш бирүдә катнашса, кабат тавыш бирү узган дип санала.»;

3 өлештә «тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар округта

теркәлгән сайлаучыларның кимендә чиреген тәшкил итсә, бүтән депутатлыкка кандидатка карата тавыш бирүдә катнашкан» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

статьяга түбәндәге эчтәлектә өлеш өстәргә:

«Халык депутатына бер генә кандидат өчен кабат тавыш биргәндә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышының кимендә 50 процентын җыйган кандидат сайланган дип санала.».

37 статья. 40 статьяда:

беренче җөмләнең 1 өлешендә «тиешле район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре бу сайлау округында кабат сайлаулар уздыру турында карар кабул итәләр» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе бу округта кабат сайлаулар билгели» дигән сүзләргә алмаштырырга;

2 өлештә «округында» сүзеннән соң «сайлаулар дөрес түгел яисә узмаган дип танылган округлардан гайре,» дип өстәргә; шуннан соң: «Бу очракта кандидатларның имза җыйган кәгазьләре үз көчендә кала.» дип язарга.

38 статья. 41 статьяда:

1 өлештә «яңа сайлаулар» дигән сүзләрне «өстәмә сайлаулар» дигән сүзләргә алмаштырырга;

2 өлештә «сайлауларга кадәр ике айдан да соңга калмыйча» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләр чоры тәмамланырга 1 елдан да кимрәк вакыт калган очракта киткән халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы депутаты урынына яңа депутатны сайлау уздырылмый.».

39 статья.

43 статьяны төшереп калдырырга. 44 статьяны 42 статья дип санарга.

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2306

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 658. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясен оештыруның һәм аның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен, статусын билгели.

1 статья. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы халык депутатларын, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны, Татарстан Республикасы референдумын әзерләү һәм уздыру өчен, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Президентын һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумын әзерләү һәм уздыру өчен оештырыла.

2. Татарстан Республикасы референдумын әзерләгәндә һәм уздырганда Комиссия Татарстан Республикасы референдумының Үзәк комиссиясе буларак эш итә.

3. Россия Федерациясе Президентын һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумын әзерләгәндә һәм уздырганда Комиссия сайлау комиссиясе вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъекты референдумы комиссиясе вазыйфаларын гамәлгә ашыра.

4. Комиссияне оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар белән билгеләнә.

5. Комиссия үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Конституциясенә, әлеге Законга, Татарстан Республикасының башка законнарына, ә Россия Федерациясе Президентын һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумын уздырганда - Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга һәм федераль законнарга таяна.

6. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр,

оешмалар сайлаулар һәм референдумнар уздыру буенча Комиссия эшенә ярдәм итәргә, тиешле белешмәләр һәм материаллар бирергә тиешләр.

7. Комиссия юридик зат була, аның сайлаулар һәм референдумнар әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелә торган федераль бюджет средстволары һәм Татарстан Республикасының Республика бюджеты средстволары өчен банк учреждениеләрендә аерым балансы һәм агымдагы аерым счетлары, герблы мөһере, штамплары, реквизитлы бланклары була.

2 статья. Комиссияне оештыру тәртибе һәм аның статусы

1. Комиссия Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә биш елга оештырыла, аның составында 15 әгъза була.

2. Комиссия ачык һәм хәбәрдарлык шартларында оештырыла.

3. Комиссия составы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана. Татарстан Республикасы Президенты Комиссия әгъзаларының яртысын һәм аның рәисен тәкъдим итә, ә аның икенче яртысын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә. Бу чакта сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары, иҗтимагый берләшмәләр, эш, хезмәт, уку, яшәү урыны буенча сайлаучылар җыелышларының һәм Комиссиянең элекке составының тәкъдимнәре исәпкә алына. Комиссия составын формалаштырганда дәүләт хезмәткәрләре Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан өчтән береннән дә күбрәк булмаска тиеш.

4. Комиссия составы республиканың массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш.

Комиссия Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы халык депутатларын, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны, Татарстан Республикасы референдумын, Россия Федерациясе Президентын һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумын әзерләү һәм уздыру өчен Татарстан Республикасында оештырыла торган сайлау комиссияләре (округ, территориаль (район, шәһәр, шәһәрләрдәге районнар), участок комиссияләре) һәм референдум комиссияләре эшчәнлегенә үз компетенциясе чикләрендә

житәкчелек итә.

6. Комиссия дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан үз компетенцияләре чикләрендә бәйсез була.

7. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Комиссия Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасын күрсәтү хокукына ия.

8. Яңа составта Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе оешканга кадәр Комиссия гамәлдә була.

3 статья. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы статусы

1. Әлеге статьяның 3 һәм 4 пунктларында санап кителгән затлардан кала, 18 яше тулган, сайлау хокукына ия булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Татарстан Республикасы гражданы Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы булырга мөмкин. Комиссия әгъзасы, кагыйдә буларак, югары белемле булырга тиеш.

2. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына мәгълүм үрнәктәге таныклык бирелә.

3. Депутатлар, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган урындагы затлары, судьялар, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатларны тәкъдим иткән сайлаучылар һәм сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары җыелышларының вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары, сайлау комиссияләренең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, кандидатларның, теркәлгән кандидатларның ирләре йә хатыннары һәм якын туганнары яисә кандидатларның, теркәлгән кандидатларның турыдан-туры буйсынуында булган затлар Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары була алмыйлар.

4. Комиссия әгъзасы бер үк вакытта бүтән сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы була алмый.

5. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы Комиссия карары буенча Комиссиядә даими нигездә (штатта торып) эшләргә мөмкин.

6. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы

вәкаләтләр чоры тәмамланганчы ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән түбәндәге очракларда Комиссия әгъзасы вазыйфаларыннан азат ителә:

Комиссия әгъзасы үз вәкаләтләрен туктату хакында язма гариза биргәндә;

Комиссия әгъзасы Татарстан Республикасы гражданлыгын югалтканда;

даими яшәү өчен Татарстан Республикасыннан читкә чыгып киткәндә;

Комиссия әгъзасына карата судның хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә Комиссия әгъзасы хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалану сәләте чикләнгән, билгесез юкка чыккан яисә вафат булган дип танылганда;

сайлау комиссиясе әгъзасы үз вазыйфаларын даими рәвештә үтәмәгәндә, Комиссия тәкъдиме буенча;

әлеге Законда каралган башка нигезләр булганда.

7. Даими нигездә (штатта торып) эшләүче Комиссия әгъзаларына акчалата түләү күләме һәм төрләре Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары белән билгеләнә.

8. Сайлаулар, референдум уздыру чорында Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына җәлеп ителә алмый яисә суд тәртибендә салына торган административ җәза чараларына тартыла алмый.

4 статья. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасының статусы

1. 18 яше тулган, сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасы гражданы Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы була ала.

2. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасының эшчәнлеге теркәлгән кандидаттан, сайлау берләшмәсеннән, сайлау блогыннан, референдум уздыру буенча инициатив төркемнән Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасын билгеләү буенча законда каралган документларны Комиссия алган мизгелдән башлана. Әлеге документларда Комиссия әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә

көне һәм ае), Татарстан Республикасы гражданлыгына ия булуы (чит дәүләт гражданлыгына ия булуы), эш урыны, шөгыленең төре һәм даими яшәү урынының тулы адресы күрсәтелә.

3. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы бер үк вакытта бүтән сайлау комиссиясе әгъзасы була алмый.

4. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасына мәгълүм үрнәктәге таныклык бирелә.

5. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасының вәкаләтләре аны билгеләп куйган затның яки органның карары белән туктатылырга һәм башка затка тапшырылырга мөмкин.

6. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре, аларны билгеләгән кандидатлар сайланган очракта, икенче сайлауларда кандидатларны теркәү тәмамланганчы дәвам итә; Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия бүтән әгъзаларының вәкаләтләре теге яки бу сайлау кампаниясе кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган барлык тавыш бирүләр буенча сайлаулар нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарганнан соң 30 көн узгач яисә референдум нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарганнан соң 10 көн узгач туктатыла.

7. Теркәлгән кандидат, сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тавыш бирү йомгакларына карата шикаять белдергәндә, Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия тиешле әгъзасының вәкаләтләре шикаятьнең асылы буенча Татарстан Республикасы Югары суды үзенең катгый карарын чыгарганнан соң туктатыла.

5 статья. Комиссиянең вәкаләтләре

1. Комиссия үз вәкаләтләре чикләрендә:

сайлаулар, референдумнар, шул исәптән, федераль сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарның Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәлешен тикшереп тора һәм аларның бер төрле кулланылуын тәэмин итә, әлеге законнарны куллану тәртибе турында аңлатмалар бирә һәм, кирәк булганда, аларны шәрехләү турында тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыга;

түбәнгерәк комиссияләрнең эшчәнлегенә юнәлеш бирә, аларга хокукый, ысулый, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны уздыру өчен район, шәһәр һәм шәһәрдәге район сайлау комиссияләрен раслый;

сайлауларны, референдумнарны әзерләүгә һәм уздыруга, сайлау системасын камилләштерүгә, сайлаучыларга хокукый белем бирүгә бәйле максатчыл программаларның гамәлгә ашырылышын тәэмин итә;

тавыш бирү өчен сайлау бюллетенен, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының рәвешен, сайлаучылар исемлеген, сайлаулар һәм референдумнар әзерләүгә һәм уздыруга бәйле бүтән төрле сайлау документларын әзерләү нормативларын (аларның саклануучанлык дәрәҗәсен дә кертеп) билгели; сайлау комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен раслый;

сайлаулар һәм референдумнар әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча сайлау округларын төзи һәм сайлау участокларының, тавыш бирү участокларының бердәм нумерациясен билгели;

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны һәм аларның ышанычлы затларын терки, аларга таныклыклар бирә;

законнарда каралган очракларда кандидатны теркәү турында, кандидатны теркәүне юкка чыгару хакында карарлар кабул итә;

законнарны бозган өчен сайлау процессында катнашучыларга карата закон нигезендә җаваплылык чаралары куллана;

барлык кандидатларга сайлау кампаниясендә катнашу өчен бертигез шартларның үтәлешен тәэмин итә;

сайлау алды үгетләве алып бару өчен теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары арасында эфир вакытын бүлүнең, тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең, сайлаулар, референдумнар нәтиҗәләрен һәм тавыш бирү йомгакларын, сайлаулар һәм референдумнар нәтиҗәләрен бастырып чыгару тәртибен билгеләүнең бердәм тәртибен саклау буенча чаралар күрә;

территория (округ) сайлау комиссияләренең сайлаучылар исемлеген үз вакытында төзүләрен тикшереп тора;

тавыш бирү йомгакларын, тулаем сайлауларның, референдумнарның нәтиҗәләрен билгели, аларны матбугатта бастырып чыгара, сайлаулар һәм референдумнар уздыруга бәйле документларны архивка тапшыруны тәэмин итә;

сайланган Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы халык депутатларын терки;

Татарстан Республикасы халык депутатлары итеп сайланган затларның исемлекләрен төзи һәм матбугатта бастырып чыгара, сайланган Татарстан Республикасы халык депутатларына вакытлы таныклыклар бирә;

кабат тавыш бирүне оештыра, кабат сайлауларны һәм киткән Татарстан Республикасы халык депутатлары урынына яңаларын сайлауны билгели;

халык депутатларын чакыртып алуны оештыруга бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

түбәнгерәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гаризаларны, шикаятьләрне карый, алар буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе белән үзара хезмәттәшлек итә;

әлеге Законда һәм башка законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Комиссия сайлаучыларның һәм сайлауларны оештыручыларның хокукый культурасын арттыру буенча, дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасын (ДАС - Сайлаулар) үстерү һәм файдалану буенча федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

6 статья. Комиссия эшчәнлеген оештыру

1. Комиссиянең яңа составы оештырылганнан соң унбишенче көненнән дә соңга калмыйча үзенең беренче утырышына җыела. Комиссиянең беренче утырышын Комиссия рәисе ача. Яңа составтагы Комиссиянең беренче утырышында Комиссиянең элекке составы әгъзалары катнашырга хокуклы.

2. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, Комиссия утырышы тулы вәкаләтле була.

Комиссия утырышлары рәис тарафыннан яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан кирәк булган саен, шулай ук аның составының кимендә өчтән бер

өлешенең таләбе буенча чакырыла.

3. Комиссия эшчәнлеге коллегиальлек, аның компетенциясендәге мәсьәләләр буенча ирекле рәвештә һәм ачыктан-ачык фикерләшү, Комиссия әгъзаларының инициативасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, Комиссия даими урнашкан урында уздырыла. Комиссия Татарстан Республикасы территориясендә күчмә утырыш уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

5. Комиссия утырышында беркетмә алып барыла.

6. Комиссия үзенең регламентын эшли һәм кабул итә.

7. Комиссия үз эшчәнлеген перспектив һәм агымдагы (календарь) эш планнары, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар әзерләү һәм уздыру буенча гамәлләр планы нигезендә башкара.

8. Комиссиянең эш планнары Комиссия регламентында каралган тәртиптә һәм вакытларда Комиссия утырышында раслана.

9. Комиссиянең Россия Федерациясе Президентын, дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны һәм Россия Федерациясе референдумын әзерләү һәм уздыру буенча, максатчыл федераль программалардагы гамәлләрне тормышка ашыру буенча эш (гамәлләр) планнары Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең эш (гамәлләр) планнары нигезендә кабул ителә.

10. Планнарны үтәүнең барышы хакындагы мәгълүмат даими рәвештә Комиссия утырышында тыңлана.

7 статья. Комиссия рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлау

1. Комиссия рәисе урынбасары һәм секретаре аның беренче утырышында сайланалар.

2. Комиссия рәисе урынбасары, секретаре Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайланалар.

3. Комиссия рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлау өчен яшерен тавыш бирү бюллетененә Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан күрсәтелгән кандидатларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре кертелә. Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавышны җыйган кандидат Комиссия рәисе

урынбасары, секретаре итеп сайланган дип санала.

4. Комиссия рәисе урынбасары, секретаре, кагыйдә буларак, югары юридик белемле булырга тиешләр.

8 статья. Комиссия карарларын кабул итү тәртибе

1. Комиссия карарлары Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан кабул ителә.

2. Комиссия рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлау йә вазыйфаларыннан азат итү турындагы, сайлауларны һәм референдумны әзерләүне һәм уздыруны финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләре буенча, кандидатларны теркәү, кандидатларны теркәүне юкка чыгару, тавыш бирү йомгаклары яисә сайлауларның, референдумның нәтиҗәләре турындагы, сайлауларны, референдумны узмаган яки гамәлгә яраксыз дип тану хакындагы, кабат тавыш бирү яисә кабат сайлаулар уздыру турындагы, түбәнгерәк комиссиянең карарын юкка чыгару һәм мәсьәләнең асылы буенча карар кабул итү турындагы Комиссия карарлары Комиссия утырышында Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Башка мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары Комиссиянең утырышта катнашучы хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

4. Комиссиянең карарларын кабул иткәндә хуплап һәм каршы бирелгән тавышлар саны бертигез булса, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5. Комиссия, бюллетеньнәр кулланып, үз компетенциясенә кергән теләсә нинди мәсьәлә буенча яшерен тавыш бирү турында карар кабул итәргә мөмкин.

6. Комиссия утырышларының карарларына һәм беркетмәләренә Комиссия рәисе яки аның урынына калган зат һәм Комиссия секретаре имза салалар.

7. Комиссия кабул иткән карар белән килешмәгән Комиссия әгъзалары язма рәвештә үзләренең аерым фикерләрен белдерергә мөмкиннәр.

8. Комиссия карарлары рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

9. Комиссия карарлары кабул ителгән көннән үз көчләренә керәләр.

10. Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары Татарстан Республикасының башкарма

хакимият органнары, дәүләт учреждениеләре, җирле үзидарә органнары, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, урындагы затлар, сайлаучылар һәм референдумда катнашучылар, шулай ук түбәнгерәк комиссияләр өчен мәҗбүри.

9 статья. Комиссия әгъзаларының вәкаләтләре

1. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы аның барлык утырышларында катнашырга тиеш. Комиссия әгъзасы мөһим сәбәпләр аркасында Комиссия утырышына килә алмаган очракта, ул бу хакта кичекмәстән Комиссия рәисенә яки секретаренә хәбәр итәргә тиеш.

2. Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Комиссия утырышлары хакында алдан хәбәр алырга;

Комиссия утырышында чыгыш ясарга, Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирүне уздыруны таләп итәргә;

Комиссия утырышында катнашучы башка затларга көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча сораулар бирергә һәм аларга нигезле җаваплар алырга;

машинадан укыла торган саклагычлардагы документларны һәм материалларны да кертеп, Комиссиянең һәм түбәнгерәк комиссияләрнең теләсә нинди документлары һәм материаллары (шул исәптән сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлеге, сайлау бюллетеньнәре, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре) белән танышырга, әлеге документларның һәм материалларның күчермәләрен (сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлегеннән, сайлау бюллетеньнәреннән, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәреннән тыш) алырга, бу күчермәләрне таныклауны таләп итәргә.

3. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыру хокукыннан, сайлау бюллетеньнәре, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре бирү, сайлау бюллетеньнәрен, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен сортировкалауда һәм санауда катнашу, тавыш бирү йомгаклары, сайлауларның нәтиҗәләре хакында беркетмәләр төзү, Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә тавыш бирүдә

катнашу һәм Комиссия карарына имза салу хокукыннан гайре, Комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына сайлауларны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча бирелгән бөтен хокукларга ия.

10 статья. Комиссия рәисенең, рәис урынбасарының, Комиссия секретаренең вәкаләтләре

1. Комиссия рәисе:

Комиссия эшенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең башка органнары, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары, урындагы затлар, сайлаучылар белән мөнәсәбәтләрдә Комиссия исеменнән эш йөртә;

сайлаучыларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына, референдум уздыру буенча инициатив төркемнәргә, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең кызыксынучы башка органнарына, оешмаларына Комиссиянең эшчәнлеге, аның тарафыннан кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат бирә;

Комиссия утырышын җыя, аның утырышларында рәислек итә;

Комиссия карарларын үтәү буенча эшләрне оештыру өчен Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

сайлаулар, референдумнар уздыру һәм комиссияләрне финанслау өчен бүлеп бирелә торган акчалар белән эш итә;

Комиссия аппараты хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

Комиссия эшчәнлеген финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итә;

Комиссия адресына килүче тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карау эшләрен оештыра;

Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән шартнамәләргә, килешүләргә һәм башка документларга имза сала;

сайлауларны, референдумнарны әзерләү һәм уздыру

чорында Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү өчен шартнамәчел нигездә белгечләр җәлеп итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы законнарында һәм федераль законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда аңа ярдәм итә, Комиссия әгъзалары арасында бүленгән вазыйфалар нигезендә конкрет юнәлешләр буенча эш оештыра, Комиссия рәисенең йомышларын үти, Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара.

Комиссия рәисе урынбасары Комиссиядә даими нигездә (штатта торып) эшли.

3. Комиссия секретаре:

Комиссия утырышларын әзерләүне тәэмин итә, эш кәгазьләрен алып баруны оештыра, Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

киләчәктә һәм агымда Комиссия эшчәнлеген планлаштыруны оештыра, аның эш планнары үтәлешенең барышын тикшереп тора;

Комиссия әгъзаларының, аппарат хезмәткәрләренең, Комиссия каршындагы органнарның һәм хезмәтләрнең Комиссия рәисе биргән йомышларны, күрсәтмәләрне үтәүләрен оператив тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

архив туплауны һәм аның саклануын тәэмин итә.

Комиссия секретаре Комиссиядә даими нигездә (штатта торып) эшли.

11 статья. Сайлауларны һәм референдумнарны әзерләүне һәм уздыруны финанс ягыннан тәэмин итү

1. Сайлауларны, референдумнарны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле гамәлләрне финанслау, сайлауларның яки референдумның дәрәҗәсенә карап, тиешле бюджеттан (федераль бюджеттан, Татарстан Республикасының республика бюджетыннан) бүлеп бирелүче акчалар исәбенә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы халык депутатларын, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны, Татарстан Республикасы референдумын әзерләү һәм уздыру буенча Комиссия чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджетында аерым юл белән

карала һәм ул бюджет чыгымнарының якланган статьялары исемлегенә кертелә.

3. Россия Федерациясе Президентын һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумнарын уздырганда Комиссия, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда, Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясенә җыелма финанс хисабы тапшыра.

Бюджет акчаларының Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы халык депутатларын, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны, Татарстан Республикасы референдумнарын әзерләү һәм уздыру өчен тотылуы турында Комиссиянең финанс хисабы билгеләнгән вакытларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла.

4. Түбәнгерәк комиссияләрнең тотылмый калган бюджет акчалары сайлаулар, референдумнар узганнан соң Комиссия счетына кайтарыла.

5. Түбәнгерәк комиссияләр тарафыннан кайтарылып, Комиссия тарафыннан тотылмый калган Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары Комиссия счетында калырга һәм Татарстан Республикасы законнарында һәм аның башка норматив-хокукый актларында каралган максатларда, шуларда билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә кулланылырга мөмкин.

12 статья. Федераль, төбәк һәм республика максатчыл программаларының гамәлләрен финанс ягыннан тәэмин итү, Комиссиягә бүлеп бирелүче акчаларны тотуның исәбен алып бару һәм хисап бирү

1. Заказчысы Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе булган федераль һәм төбәк максатчыл программаларының гамәлләрен финанс ягыннан тәэмин итү федераль бюджеттан бүлеп бирелүче акчалар исәбенә башкарыла.

2. Республика программаларының сайлау системасын үстерүгә, шул исәптән яңа сайлау технологияләрен, автоматлаштыру чараларын гамәлгә кертүгә, сайлаучыларга һәм сайлауларны оештыручыларга хокукый белем бирүгә бәйле гамәлләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелүче

акчалар исәбенә башкарыла.

3. Программаларның гамәлләре (юнәлешләре) буенча бирелгән бюджет акчаларын бүлү Комиссия карары белән раслана.

4. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларның керүе һәм тотылуы хакында Комиссия аерым бухгалтер исәбе алып бара.

5. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү һәм федераль максатчыл программаларны гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән акчаларның тотылуы турында бухгалтер хисабын һәм шулай ук финанс хисабын Комиссия Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшыра.

6. Комиссия рәисе акчага хуҗа була һәм финанс документларының финанс мәсьәләләре буенча Комиссия кабул иткән карарларга туры килү-килмәве өчен, финанс хисапларының федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшырылуы өчен җаваплы була.

13 статья. Комиссия аппараты

1. Комиссия эшчәнлеген хокукый, оештыру-ысулый, мәгълүмати-аналитик, финанс, нәшрият, матди-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итүне Комиссия аппараты гамәлгә ашыра.

2. «Дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына таянып төзелгән дәүләт хезмәткәрләре реестры нигезендә Комиссия аппараты хезмәткәрләре дәүләт хезмәткәрләренә керәләр.

3. Комиссия аппаратына гомуми җитәкчелек итүне Комиссия рәисе гамәлгә ашыра. Комиссия аппаратының эшен оештыру Комиссия секретарена йөкләнә.

4. Комиссия аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, вазыйфалары һәм җаваплылыгы Комиссия тарафыннан расланган вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

14 статья. Комиссия каршындагы контроль-ревизия хезмәте

1. Сайлаулар, референдумнар әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчыл тотылуын тикшереп тору өчен, шулай ук керемнәр керү чыганакларын, сайлау

фондларының, референдумда катнашучы фондларның акчаларын дөрес исәпкә алуны һәм куллануны тикшереп тору өчен, кандидатларның, теркәлгән кандидатларның, сайлау блокларының финанс хисапларын тикшерү өчен Комиссия каршында Контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Комиссия каршындагы Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Комиссия тарафыннан раслана.

15 статья. Комиссиядә тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карау

1. Комиссия федераль законнарның, Татарстан Республикасы законнарының сайлауларны, референдумнарны әзерләүне һәм уздыруны җайга салучы өлешләренең бозылуы турындагы тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне үз компетенциясе чикләрендә карарга, алар буенча тикшерүләр үткәрергә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә законда билгеләнгән вакытларда җавап бирергә тиеш.

2. Комиссия тарафыннан тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карау тәртибе закон нигезендә Комиссия регламентында билгеләнә.

3. Тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне караганда Комиссия утырышында кызыксынучы якларның вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

4. Утырышта кабул ителгән карар турында Комиссия мөрәҗәгать итүчегә яисә кызыксынучы якларның вәкилләренә законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда хәбәр итә, аларның үтенече буенча аларга карарның таныкланган күчермәсен бирә.

16 статья. Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

Әлеге Закон нормаларын бозучы затлар закон нигезендә административ йә җинаяти җаваплы булалар.

17 статья. Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Закон кабул ителүгә бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Югары Советының 1995 елның 18 гыйнварендагы 2300-XII номерлы «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карары (Татарстан Республикасы Югары Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, №

1);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 5 июлендәге 172 номерлы «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы карары (Татарстан Дәүләт Советының Җыелма басмасы, 1995 ел, № 7-8) үз көчләрен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2307

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 659. «Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 3; 1994 ел, № 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997 ел, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 1 статьяның беренче өлешендәге икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәге түләү рәвешләре була: җир салымы, шулай ук дәүләт милкендәге, җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә, гомерлек мирас итеп биләүгә, файдалануга, шул исәптән арендага тапшырганда аренда түләве һәм бер мәртәбә түләнә торган түләүләр, моңа торак пунктының инженерлык һәм табигатьне саклау инфраструктурасын торгызу өчен түләү дә керә».

1 статьяның икенче өлешендәге икенче җөмләсендә «арендага» сүзе алдыннан «дәүләт милкендәге, җирле үзидарә милкендәге җирләрдән» дип өстәргә.

2 статья. 5 статьяның икенче өлешендә, 10 һәм 13 статьяларда «административ» сүзен төшереп калдырырга.

5 статьяның өченче өлешендә «Советлары» сүзеннән соң, 6 статьяның өченче өлешендә «Советларына» сүзеннән соң, 7 статьяның икенче өлешендә «Советлары» сүзеннән

соң, 17 статьяның алтынчы өлешендә «Советлары» сүзеннән соң, 18 статьяның беренче абзацында «Советларының» сүзеннән соң тиешле килешләрдә «җирле үзидарә органнары» дигән сүзләр өстәргә.

3 статья. 5 статьяның өченче өлешендә, 6 статьяның өченче өлешендә, 18 статьяның өченче һәм дүртенче абзацларында «шәһәр» сүзеннән соң «(берләштерелгән)» сүзен өстәргә.

4 статья. 6 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, беренче һәм икенче өлешләр белән алыштырырга:

«Авыл торак пунктлары яисә бакчачылык ширкәтләре чикләрендә гражданнарга индивидуаль һәм күмәк бакчачылык һәм терлекчелек, шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен бирелгән кишәрлекләр өчен җир салымы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раслый торган ставкалар буенча җир кишәрлегенең барлык мәйданыннан чыгып билгеләнә.

Гражданнарга һәм юридик затларга башка максатлар өчен авыл торак пунктлары чикләрендә бирелгән кишәрлекләр өчен салым 20 меңгә кадәр кешеле торак пунктлар өчен җир салымына билгеләнгән ставка нигезендә исәпләнә».

6 статьяның икенче һәм өченче өлешләрен өченче һәм дүртенче өлешләр дип санарга.

5 статья. 7 статьяның беренче өлешендә «шәһәрләрдәге, эшчеләр поселокларындагы» дигән сүзләрне «республика буйсынуындагы шәһәрләрдәге, шәһәр торак җирләрендәге» сүзләре белән алыштырырга.

7 статьяның икенче өлешендә «даими кулланылышка һәм биләүгә бирү белән бәйле» сүзләрен «гражданнар һәм юридик затлар милкенә, гомерлек мирас итеп биләүгә, файдалануга, шул исәптән арендага» сүзләре белән алыштырырга, «шәһәрләрнең» дигән сүздән соң «һәм поселокларның» сүзләрен «һәм башка торак җирләренең» сүзләре белән алыштырырга.

6 статья. 9 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торaклардан читтә урнашкан сәнәгать (җитештерү

эшчәнлеге белән бозылган карьерларны һәм территорияләрне дә кертеп), элемтә һәм транспорт, радиотапшырулар, телевидение җирләре һәм махсус билгеләнештәге бүтән җирләр өчен салым халкы 20 меңгә кадәр булган торак җирләр өчен билгеләнгән җир салымының уртача ставкаларыннан 20% күләмендә билгеләнә».

9 статьяның икенче өлешендәге «торак пунктларыннан читтә урнашкан һәм аэродромнар» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

7 статья. 12 статьяның беренче өлешендәге беренче абзацында «түбәндәге физик һәм юридик затлар» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

12 статьяның беренче өлешендәге 3 пунктында «дәүләт бюджеты» сүзләрен «тиешле бюджет акчалары» сүзләре белән алыштырырга, «сәламәтлек саклау» дигән сүзләрдән соң «социаль хезмәт күрсәтүнең дәүләт учрежденияләре» дигән сүзләр өстәргә.

12 статьяның беренче өлешендәге 4 пунктында «ихтыяҗлары өчен яңадан торгызуны» дигән сүзләрдән соң «яисә туфрак уңдырышлылыгын күтәрү өчен файдаланылучы торф чыгару максатларында» дигән сүзләр өстәргә.

12 статьяның беренче өлешендәге 5 пунктында «элеккеге партизаннар» дигән сүзләрдән соң «шулай ук Бөек Ватан сугышында катнашучыларга законнарда каралган социаль гарантияләр һәм өстенлекле ташламалар бирелгән гражданнар» дигән сүзләр өстәргә, ә «һәм аларга тиңләштерелгән гражданнарның категорияләре» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

12 статьяның беренче өлешендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) инвалидлар; авыл җирендә яшәүче һәм пенсиягә чыккан ялгыз пенсионерлар»;

12 статьяның беренче өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Чернобыль АЭСендәге һәлакәт һәм граждани яисә хәрби атом объектларындагы бүтән төрле радиация аварияләре нәтиҗәсендә, шулай ук, атом-төш һәм галәм техникасын да кертеп, атом-төш җайланмаларының теләсә кайсы төренә бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм бүтән эшләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар ителгән гражданнар».

12 статьяның беренче өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) торак пунктларының һәм коммуналь хуҗалыкның гомуми файдалану җирләре».

12 статьяның беренче өлешендәге 12 пунктында «объектлары» сүзеннән соң «су юлларының һәм гидрокорылмаларның дәүләт унитар предприятиеләре, һава һәм елга транспорты дәүләт оешмалары, шул исәптән су белән капланган җирләр өчен һәм гидротехник корылмалар төзегәндә ясалма рәвештә булдырылган территорияләр һәм гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары, аэродромнар, аэропортлар биләп торучы җирләр» дигән сүзләр өстәргә.

12 статьяның беренче өлешендәге 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) инвалидларның җәмәгать берләшмәләре, алар милкендәге оешмалар, устав капиталы тулысынча инвалидларның җәмәгать берләшмәләре кертемнәреннән торучы хуҗалык җәмгыятьләре».

8 статья. 12 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядәге 15, 16, 17, 18, 19, 20, 21, 22, 23 пунктлар белән тулыландырырга:

«15) дәүләт бюджеты исәбеннән финанслана торган фәнни-тикшеренү учреждениеләре;

16) очып китү-төшеп утыру полосаларын һәм очуларны тәэмин итү хезмәтләрен урнаштырган җир кишәрлекләре өчен дәүләт оешмалары;

17) хәрби хезмәткәрләр, хәрби хезмәттә булуның чик яшенә җитеп, сәламәтлеге буенча яисә оештыру-штат гамәлләренә бәйле рәвештә хәрби хезмәттән азат ителгән һәм хәрби хезмәттә гомуми алганда егерме ел һәм аннан да артыграк булган гражданнар, хәрби вазыйфалар башкарганда туендыручылары һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, җинаятьләрне үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең гаилә әгъзалары;

18) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Дан, Хезмәт Даны һәм «СССР Кораллы көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнарының тулы кавалерлары;

19) җинаять җәзасын үтәтү системасы учреждениеләре

һәм органнары;

20) һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре;

21) янгыннан саклаучылар тарафыннан файдаланылучы җирләр;

22) эчке, тимер юл һәм чик буе гаскәрләре, граждан оборонасы гаскәрләре, аларны урнаштыру һәм аларның даими эшчәнлеге өчен бирелгән җирләр өчен;

23) дәүләт мелиорация системаларын һәм аерым торган гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре, шул исәптән сусаклагычлар, каналлар, дамбалар һәм аларны киртәләү полосалары чикләрендә башка гидротехник корылмалар белән су фонды җирләре өчен, шулай ук дәүләт мелиорация системалары һәм аерым торган гидротехник корылмалар төзүче дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре әлеге объектларны төзү өчен үзләренә вакытлыча бирелгән җирләр өчен».

9 статья. 12 статьяны түбәндәге редакциядәге өченче, дүртенче һәм бишенче өлешләр белән тулыландырырга:

«Тимер юл киртәләве полосасында урнашкан җирләргә тимер юл транспорты оешмаларыннан салым авыл хуҗалыгының ундырышлы җирләре өчен билгеләнгән җир салымы ставкасының 25% күләменә кадәр салына.

Җир салымы түләүдән азат ителгән юридик затларга һәм гражданнарга, алар җир кишәрлекләрен арендага (файдалануга) тапшырганда, җир салымы арендага (файдалануга) тапшырылган мәйданга салына.

Мобилизация билгеләнешендәге объектлар, консервацияләнгән һәм агымдагы җитештерүдә файдаланылмый торган мобилизация куәтләре, сынау полигоннары, мобилизация резервының һәм мобилизация запасларының матди хәзинәләрен саклау складлары урнаштырылган җирләрдән файдаланган өчен җир салымы, аренда түләве һәм башка түләүләр алынмый».

10 статья. 13 статьяда «киметә ала һәм» сүзләрен «җир салымының Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче суммасы чикләрендә» сүзләре белән алыштырырга.

11 статья. 14 статьяның беренче өлешендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнары, халык депутатларының район, шәһәр (берләштерелгән) Советлары үз карамакларында кала торган сумма чикләрендә түбәндәгеләр өчен җир салымы буенча өстенлекле ташламалар билгеләргә хокуклы:».

14 статьяның өченче өлешен төшереп калдырырга.

12 статья. 17 статьяның җиденче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Үз вакытында җир салымы түләүгә җәлеп ителмәгән түләүчеләр аны узган өч елдан артыкка түләмиләр. Дөрес салынмаган салымны яңадан карау узган өч ел өчен генә рөхсәт ителә».

13 статья. 18 статьяның беренче абзацында «халык депутатларының авыл Советлары» дигән сүзләрне «җирле үзидарә органнары» дигән сүзләр белән алыштырырга; «авыл торак пунктлары чикләрендәге» дигән сүзләрне «җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләрендәге» дигән сүзләр белән алыштырырга.

18 статьяның өченче абзацында «поселоклар», «(поселок)» сүзләрен төшереп калдырырга.

18 статьяның дүртенче абзацында «административ» сүзен төшереп калдырырга, «авыл, поселок» дигән сүзләрне «җирле үзидарә органнары» дигән сүзләр белән алыштырырга.

14 статья. 19 статьяда «Татарстан» сүзен «Татарстан Республикасы» сүзе белән алыштырырга, «административ» сүзен төшереп калдырырга, «шулай ук шәһәрләр һәм поселоклар җирләре өчен» дигән сүзләрне «республика буйсынуындагы шәһәрләр җирләре өчен, шәһәр җирләре өчен, район үзәкләре булган авыл торак җирләре өчен, шулай ук бакчачылык ширкәтләре, сәнәгать, элемтә һәм транспорт, радиотапшырулар, телевидение җирләре һәм торак пунктларыннан читтә урнашкан махсус билгеләнештәге бүтән җирләр өчен; халык депутатларының район, шәһәр (берләштерелгән) Советларының махсус бюджет счетларына - җир салымыннан һәм район үзәкләре булмаган авыл торак пунктлары җирләре өчен аренда түләүләре суммасыннан - 50%» сүзләре белән алыштырырга.

15 статья. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җир өчен аренда түләвенең күләме, шартлары һәм вакытлары шартнамә белән билгеләнә. Дәүләт милкендәге

җирләрне арендалаганда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты җирләрдән файдалану төрләре һәм арендачылар категорияләре буенча аренда түләвенең база күләмнәрен билгели. Аренда түләве акчалата да, натуралата да билгеләнергә мөмкин».

16 статья. 23 статьяның беренче өлешендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт милкендәге, җирле үзидарә милкендәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә, гомерлек мирас итеп биләүгә, файдалануга, шул исәптән арендага тапшырганда, җир салымы, шулай ук аренда түләве һәм бер мәртәбә түләнә торган түләүләр тиешле бюджетларның керемнәрендә һәм чыгымнарында аерым юл белән исәпкә алыналар һәм бары тик түбәндәге максатлар өчен генә тотылалар:».

17 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2308

## Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен